МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

07.11.2024 Казан ш. № 655-пр

Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, милек итеп, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

1. Тәкъдим ителгән Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, милек итеп, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын расларга.

2. Көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, милек итеп, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында 11.05.2023 № 316-пр боерыгын;

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының "Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының кайбер боерыкларына үзгәрешләр кертү турында" 26.09.2023 № 684-пр боерыгының 1 пунктын;

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының "Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының кайбер боерыкларына үзгәрешләр кертү турында" 11.04.2024 № 207-пр боерыгының 3 пунктын.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасары А.И. Галиевка йөкләргә.

**Министр** **А.Р.Кадыйров**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
07.11.2024 № 655-пр
боерыгы белән расланды

Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, милек итеп, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, милек итеп, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, милек итеп, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартларын һәм тәртибен билгели, һәм Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләренә карый.

1.2. Гариза бирүчеләр булып түбәндәгеләр санала:

җир кишәрлекләрен милек итеп, арендага биргәндә - дәүләт милкендә булган җир кишәрлекләрен сатулашуларсыз гына алырга хокукы булган физик һәм юридик затлар, Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{10}$, $39^{20}$ статьясында (алга таба – РФ ҖК) каралган очраклар, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләрен крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлеге алып бару өчен гражданнарга яки крестьян (фермер) хуҗалыкларына арендага бирү искәрмә булып тора;

җир кишәрлекләрен даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга биргәндә - дәүләти һәм муниципаль учреждениеләр (бюджет, казна, автоном), казна предприятиеләре, үз вәкаләтләрен үтәүдән туктаган Россия Федерациясе президентларының тарихи мирасы үзәкләре, «Банк России»;

җир кишәрлекләрен түләүсез файдалануга биргәндә - Россия Федерациясе Җир кодексы, федераль законнар, Татарстан Республикасы Җир кодексы һәм башка Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән, әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында күрсәтелгән гражданнар һәм юридик затлар.

Гариза бирүче исеменнән тиешле тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә вәкаләтләр бирелгән зат эш йөртә.

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә профилирование (гариза бирүчегә дәүләт хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан үткәрелгән анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән гариза бирүче билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү вариантына тәңгәл килгән дәүләт хезмәте күрсәтү) үткәрелми.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү атамасы

Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, милек итеп, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү.

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган атамасы

Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – Министрлык).

Дәүләт хезмәте күрсәтүдә хезмәттәшлек турында тиешле килешүе булган очракта, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәкләр (алга таба – МФЦ) катнаша.

Дәүләт хезмәте күрсәтү физик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр өчен - яшәү урынына яисә фактик яшәгән (торган) урынына карамастан, юридик затлар өчен – урнашкан урынына карамастан экстерриториаль принцип буенча гариза бирүче сайлап алган теләсә кайсы МФЦда башкарыла ала.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган запросны һәм документларны һәм (яки) мәгълүматны кабул итүдән баш тарту турында карар МФЦ тарафыннан әлеге Регламентның 2.7 пункты таләпләренә туры китереп кабул ителә.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

1) сату-алу шартнамәсе проекты; җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе проекты яки җир кишәрлегеннән түләүсез файдалану шартнамәсе проекты, шулай ук, күрсәтелгән шартнамә проектларын имзалау өчен гариза бирүчегә юллау;

2) җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирү турында карар (әлеге Регламентка 2 нче кушымта);

3) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар (җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, милеккә бирүдән баш тарту турында карар; җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, арендага бирүдән баш тарту турында карар; җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирүдән баш тарту турында карар; җир кишәрлеген түләүсез файдалануга бирүдән баш тарту турында карар) (әлеге Регламентка 3 нче кушымта).

2.3.2. Җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирү турында карар Министрлык боерыгы формасында кабул ителә.

2.3.3. Җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирү турында карар реквизитлары:

карарның номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле орган атамасы;

гариза бирүченең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булса) (физик зат өчен);

юридик зат атамасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле зат вазифасы (алга таба – вәкаләтле зат);

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булса);

электрон имза турында белешмә (җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирү турында карарны электрон имза белән имзалаганда).

Җир кишәрлеген сату-алу шартнамәсе (җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе, җир кишәрлеген түләүсез файдалану шартнамәсе) реквизитлары:

шартнамә төзүгә вәкаләтле орган атамасы;

шартнамә имзаларга вәкаләтле зат вазифасы (алга таба – вәкаләтле зат);

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булса);

гариза бирүченең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булса) (физик зат өчен);

юридик зат атамасы;

фамилия, имя и отчество (последнее – при наличии) представителя заявителя;

гариза бирүче вәкиленең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булса);

электрон имза турында белешмә (шартнамәне электрон имза белән имзалаганда).

2.3.4. Реестр язуы дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып тормый.

2.3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе нинди дә булса Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмати системасында теркәлми.

2.3.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе гариза бирүчегә “Электрон имза турында” 2011 елның 6 апрелендәге № 63-ФЗ Федераль закон (алга таба - Федераль закон № 63-ФЗ) таләпләренә туры китереп көчәйтелгән электрон имза белән министр тарафыннан (җир кишәрлеген милеккә тапшырган очракта), министрның беренче урынбасары тарафыннан (җир кишәрлеге башка хокукларда тапшырылганда) имзаланган электрон документлар рәвешендә Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталында (https:// www.gosuslugi.ru/), (алга таба – Бердәм портал), Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы (https://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба – Республика порталы) гариза бирүченең шәхси кабинетына юллана.

2.3.7. Гариза бирүче сайлавы буенча дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе Министрлыктан җибәрелгән, кәгазьгә бастырылган, МФЦ мөһере һәм МФЦ хезмәткәре имзасы белән расланган электрон документ экземпляры формасында МФЦ аша алынырга мөмкин.

2.3.8. Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында яки электрон документның кәгазь экземпляры формасында алырга мөмкин.

2.3.9. Гариза бирүче шәхсән үзе Министрлыктан әлеге Регламентның 2.3.1 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазь сыйфатында алырга мөмкин.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы

2.4.1. Гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар гариза бирүче тарафыннан почта аша юлланылган яки шәхси тапшырылган булса, дәүләт хезмәте гариза һәм документлар Министрлыкта регистрацияләнгән көннән соң 15 эш көне эчендә күрсәтелә.

2.4.2. Гариза бирүче гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны Бердәм портал, Республика порталында гариза бирүченең шәхси кабинеты аша тапшырса, эш номенклатурасына туры китереп гаризага Бердәм портал, Республика порталының шәхси кабинетында күренеп торган номер һәм «Документларны тикшерү» статусы бирелгәннән соң дәүләт хезмәте Министрлык тарафыннан 15 эш көне эчендә күрсәтелә.

2.4.3. Гариза бирүче гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны гариза МФЦ аша тапшырган икән, Министрлык тарафыннан дәүләт хезмәте гариза һәм документлар регистрацияләнгәннән соң 15 эш көне эчендә күрсәтелә, шулай ук, МФЦ Регламенты белән каралган срок та исәпкә алына.

2.4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документ гариза бирүче сайлаган ысул белән, шул исәптән, электрон документ формасында, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе формалаштырылган һәм регистрацияләнгән көнне җибәрелә.

2.4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документлар гариза бирүче Министрлыкка мөрәҗәгать иткән көнне тапшырыла.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр

Бердәм порталда, Республика порталында түбәндәгеләр урнаштырыла:

дәүләт хезмәте күрсәтүне көйләүче норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмә;

дәүләт хезмәте күрсәтүче Министрлыкның һәм Министрлыкның вазыйфаи затының карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларның тулы исемлеге.

2.6.1. Дәүләт хезмәте алу өчен гариза бирүче мөрәҗәгатенең категориясенә һәм нигезенә карамастан, гариза тапшыра:

- МФЦга яки Министрлыкның үзенә мөрәҗәгать иткән очракта кәгазь документ рәвешендә (әлеге Регламентка 4 нче кушымта);

- Бердәм портал, Республика порталы аша мөрәҗәгать итсә, электрон формада (гаризаның электрон формасына тиешле белешмәләрне кертү юлы белән тутырыла), әлеге Регламентның 2.6.5 пункты таләпләренә туры китереп имзалана.

2.6.2. Гариза бирүче Министрлыкка мөрәҗәгать иткәндә гариза белән бергә түбәндәге документларны тапшыра:

2.6.2.1. Җир кишәрлеген сатулашулар уздырмыйча милеккә, арендага бирү өчен:

1. Гариза бирүченең җир кишәрлеген сатулашулар уздырмыйча милеккә, арендага алу хокукын раслаган һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләтләре билгеләнгән башкарма хакимиятнең федераль органы исемлеге белән каралган документлар, Министрлыкка ведомствоара мәгълүмати арадашлык тәртибендә бирелергә тиешле документлар искәрмә булып тора;

2. Физик зат булган гариза бирүченең (гариза бирүчеләрнең) яки физик яисә юридик зат вәкиленең шәхесен раслаган документ күчермәсе (Бердәм портал, Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә таләп ителми);

3. Җир кишәрлеген сатулашулар уздырмыйча милеккә, арендага бирү турында мөрәҗәгать белән гариза бирүченең вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта – гариза бирүченең вәкаләтләрен раслаучы документ;

4. Гариза бирүче чит ил юридик заты булган очракта, юридик затның чит дәүләт законнарына туры китереп дәүләт регистрациясен үтүе турында рус телендә расланган тәрҗемәсе;

5. Җир кишәрлеген сатулашулар уздырмыйча милеккә (арендага) бирү турында мөрәҗәгать белән коммерцияләшмәгән бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәте чыккан булса, әлеге ширкәт тарафыннан әзерләнгән аның әгъзалары реестры.

Әлеге документлар Министрлыкка җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында мөрәҗәгать белән юлланган булса, әлеге мөрәҗәгатьне карап җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында карар кабул ителгән булса, күрсәтелгән документларны тапшыру таләп ителми.

РФ ҖК $39^3$ статьясының 2 пунктындагы 7 подпунктында, РФ ҖК $39^6$ статьясының 2 пунктындагы 11 подпунктында каралган очракларда җир кишәрлеген сатулашулар уздырмыйча гына милеккә (арендага) бирү турында мөрәҗәгать әлеге җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) куллануның туктатылуы турында мөрәҗәгать белән бергә тапшырылырга тиеш.

Татарстан Республикасы милке булган җир кишәрлекләрен гражданинга яки юридик затка милеккә яки арендага бирү очракларының исемлеге әлеге Регламентның 11 нче, 12 нче кушымталарында китерелгән.

Гариза бирүче тапшыра торган өстәмә документлар исемлеге, хезмәтне алучының категориясенә карап, әлеге Регламентның 13 нче, 14 нче кушымталарында китерелгән.

2.6.2.2. Җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында бирү өчен:

1. Юридик зат вәкиленең шәхесен раслаучы документ күчермәсе.

2. Юридик зат вәкиленең вәкаләтен раслаучы документ күчермәсе.

Гариза бирүче бирергә тиешле өстәмә документлар исемлеге, күрсәтелгән хезмәтләрне алучының категориясенә бәйле рәвештә әлеге Регламентка 15 нче кушымтада китерелгән.

2.6.2.3. Җир кишәрлеген түләүсез файдалану хокукы белән алу өчен:

1. Физик зат булган гариза бирүченең (гариза бирүчеләрнең) шәхесен яисә физик яки юридик зат вәкиленең шәхесен раслаучы документ күчермәсе.

2. Гариза бирүченең (гариза бирүчеләрнең) вәкиле мөрәҗәгать итсә, физик яки юридик зат вәкиленең хокукын (вәкаләтләрен) раслаучы документ күчермәсе.

Гариза бирүче бирергә тиешле өстәмә документлар исемлеге әлеге Регламентка 16 нчы кушымтада китерелгән.

2.6.3. Гариза һәм аңа теркәлгән документлар гариза бирүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырыла (юллана) ала:

1) шәхсән (ышанычнамә нигезендә гариза бирүче исеменнән эш йөрткән зат) яки кәгазь документлар рәвешендә почта элемтәсе аша. Гариза һәм аңа теркәлгән документлар почта аша юлланган очракта тиешле тәртиптә раслана.

2) МФЦ аша кәгазь документлар белән һәм “Электрон имза турында”2011 елның 6 апрелендәге № 63-ФЗ Федераль закон таләпләренә туры китереп имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендә;

3) Бердәм портал, Республика порталы аша электрон формада.

2.6.4. Гаризаны ышанычнамә буенча формалаштырганда вәкаләтле зат паспортын (шәхесен раслаучы башка документ), нотариаль расланган ышанычнамә яки законнарга таянып нотариаль расланганга тиңләштерелгән ышанычнамә бирелә.

Гаризага беркетелгән документлар нотариаль раслана ала. Нотариаль расланган күчермә булмаган очракта түбәндәгеләр шул ук дәрәҗәдә кабул ителергә тиеш:

төп нөсхәгә туры килүе турында оешма җитәкчесе яисә шул вазыйфага вәкаләтле зат имзалаган һәм оешма мөһере (булса) куелган документ күчермәсе;

документның төп нөсхәсе күрсәтелгән очракта расланмаган күчермәләр. Бу очракта документ күчермәсен аны кабул итүче раслый.

2.6.5. Физик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр гаризаны һәм кирәкле документларны Бердәм портал, Республика порталы аша җибәргәндә гаризага гади электрон имза куялар.

Гариза бирүчегә гади электрон имза алу өчен Электрон рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмати системаларның мәгълүмати-технологик арадашлыгын тәэмин итүче инфраструктурада идентификация һәм аутентификациянең бердәм системасында (алга таба – ЕСИА) регистрация (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук учет язуын стандарттан да ким булмаган дәрәҗәдә расларга кирәк.

Россия Федерациясе территориясендә регистрацияләнгән юридик затлар һәм юридик затларның вәкилләре гаризаны һәм кирәкле документларны Бердәм портал, Республика порталы аша юллаганда гаризаны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалыйлар.

Гариза бирүче вәкиленең электрон документ (документның электрон образы) рәвешендәге ышанычнамәсе әлеге документларны ясау һәм имзалау вәкаләте булган затларның, шул исәптән, нотариусларның тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән раслана.

Гаризага теркәлгән электрон документлар (документның электрон образы), шул исәптән, ышанычнамәләр 50 Мбайттан да артык булмаган үлчәмдәге pdf, jpg, jpeg, png, tif, doc, docx, rtf форматрлы файллар рәвешендә җибәрелә.

Тапшырылган электрон документларның (документларның электрон образы) сыйфаты документ текстын тулысынча укырга һәм документ реквизитларын танырга мөмкинлек бирергә тиеш.

2.6.6. Ведомствоара мәгълүмати арадашлык кысаларында алына торган документлар:

2.6.6.1. Җир кишәрлеген сатулашулар уздырмыйча милеккә, арендага бирү өчен:

1. Соралган җир кишәрлеге турында Күчемсез милек бердәм дәүләт реестрыннан (алга таба - ЕГРНнан өземтә) өземтә, «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалыннан (алга таба – ТР ФКП).

2. Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан юридик зат турында яисә Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан шәхси эшмәкәр турында өземтә -

Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә (алга таба – ТР буенча ФСХИ);

3. Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан (алга таба – РФ ФПСС) инвалидлык турында белешмә (инвалидлык төркемен күрсәтеп, инвалидлык билгеләнүен раслаучы белешмә; инвалидны, инвалид баланы реабилитацияләү яки абилитацияләүнең индивидуаль программасы), мәгълүмат «Инвалидларның Федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмати системасында (ФГИС ФРИ) була, гражданин (торакны яллаучы) инвалид булса яки аның гаиләсе составында инвалид булса;

4. Гариза бирүченең җир кишәрлеген сатулашулар уздырмыйча алу хокукын раслаган Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең «Гариза бирүченең җир кишәрлеген сатулашулар уздырмыйча алу хокукын раслаучы документларны раслау турында» 2020 елның 2 сентябрендәге № П/0321 Боерык белән расланган документлар исемлегендә каралган башка документлар һәм белешмәләр, дәүләт хакимиятенең вәкаләтле федераль органыннан, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органыннан, җирле үзидарә органыннан.

Министрлык тарафыннан соралган җир кишәрлеген сатулашулар уздырмыйча милеккә, арендага бирү хокукын раслаган документлар исемлеге, күрсәткән хезмәтләрне алучының категориясенә бәйле рәвештә, әлеге Регламентның 13 нче, 14 нче кушымталарында күрсәтелгән.

2.6.6.2. Җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында бирү өчен:

1. Соралган җир кишәрлеге турында ЕГРНнан өземтә, ТР ФКПтан.

2. Гариза бирүче булган юридик зат турында ЕГРЮЛдан өземтә, ТР буенча ФСХИдан.

Министрлыктан соралган җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында бирү хокукын раслаган документлар исемлеге, күрсәткән хезмәтләрне алучының категориясенә бәйле рәвештә, әлеге Регламентның 15 нче кушымтасында күрсәтелгән.

2.6.6.3. Җир кишәрлеген түләүсез файдалану хокукында бирү өчен:

1. Соралган җир кишәрлеге турында ЕГРНнан өземтә, ТР ФКПтан.

2. Күчемсез милек объекты турында (соралган җир кишәрлегендә урнашкан бина һәм (яки) корылмалар турында) ЕГРН өземтәсе, ТР ФКПтан.

3. Гариза бирүче булган юридик зат турында ЕГРЮЛдан өземтә, ТР ФСХИдан.

4. Коммерциячел булмаган оешма төзү турында карар күчермәсе (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органыннан) – җир кишәрлеген аерым категория гражданнарны торак белән тәэмин итү өчен торак төзелеше максатларында Татарстан Республикасы законнарында каралган һәм Татарстан Республикасында төзелгән коммерциячел булмаган оешмага биргән очракта.

5. Күчемсез милек объекты турында (соралган җир кишәрлегендә урнашкан биналар, корылмалар турында) ЕГРН өземтәсе (бина, корылма төзелгән очракта кирәкми) – җир кишәрлеген дини яки хәйрия билгеләнешендәге биналар, корылмалар төзү өчен дини оешмага биргәндә.

6. Россия Федерациясе Хезмәт кодексының $66^1$ статьясында (алга таба – РФ ХК) билгеләнгән тәртиптә алынган хезмәт эшчәнлеге турында белешмә (2020 елның 1 гыйнварыннан соңгы чор өчен) Россия Федерациясе Пенсия фондыннан яки Гариза бирүченең соңгы эш урыны буенча эш бирүчедән (гражданнар өчен).

Министрлыктан соралган җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында бирү хокукын раслаган документлар исемлеге, күрсәткән хезмәтләрне алучының категориясенә бәйле рәвештә, әлеге Регламентның 16 нчы кушымтасында күрсәтелгән.

2.6.7. Гариза бирүче Регламентның 2.6.6.1, 2.6.6.2, 2.6.6.3 пунктларында күрсәтелгән документларны (белешмәләрне) Бердәм портал, Республика порталы аша биргәндә әлеге документларны булдыру һәм имзалау өчен вәкаләтле затларның көчәйтелгән квалификацияле имзасы куелган электрон документ формасында бирә ала яки МФЦга кәгазь формасында.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.7.1. Гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән гариза бирүчеләр категориясенә кермәгән зат мөрәҗәгать иткән;

2) гаризада һәм аңа беркетелгән документларда тиешле тәртиптә расланмаган чистартулар, өстәп язулар һәм төзәтүләр булу.

2.7.2. Гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны кире кайтару өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) гариза Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{17}$ статьясының 1 пункты нигезләмәләренә туры килми (алга таба – РФ ҖК);

2) документлар тиеш булмаган органга тапшырылган;

3) әлеге Регламентның 2.6.2 пункты нигезендә гариза бирүче шәхсән үзе тапшырылырга тиешле документларның тапшырылмавы.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр законнарда каралмаган.

2.8.2. Җир кишәрлеген милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән), түләүсез файдалануга бирүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 5 кушымтасындагы бер генә шартның булуы да нигез булып тора.

2.8.3. Баш тарту сәбәпләре күрсәтелгән Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кәгазьгә чыгарылып тиешле тәртиптә министрның беренче урынбасары тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көнне гариза бирүчегә һәм (яки) МФЦга җибәрелә.

Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен сорап Бердәм портал, Республика порталы аша мөрәҗәгать итсә, гариза бирүченең шәхси кабинетена министрның беренче урынбасары көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куйган дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документның электрон образы җибәрелә.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төрле түләүнең тәртибе, күләме һәм алу нигезләре

Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын түләү һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә Бердәм портал, Республика порталын, рәсми сайтны кулланып алына торган башка түләүләр юк. Дәүләт хезмәте түләүсез күрсәтелә.

2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында запрос биргәндә һәм андый хезмәтләрне күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь срогы

Дәүләт хезмәте алу өчен гариза биргәндә максималь көтү вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда алдан язылу буенча килеп чиратны максималь көтү вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләренә чират тәртипләре билгеләнмәгән.

2.11. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне сораган гариза бирүченең запросын регистрацияләү срогы

2.11.1. Запрос һәм документлар кергән бер көн эчендә.

Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада кергән запрос ял (бәйрәм) көненнән соң килгән эш көнендә регистрацияләнә.

Гариза бирүче яки аның вәкиле тарафыннан МФЦ аша бирелгән запрос Министрлык тарафыннан МФЦдан кергән көнне регистрацияләнә.

2.11.2. Гариза бирүче МФЦга шәхсән үзе мөрәҗәгать итсә, шул көнне аңа АИС МФЦдан гаризаның җибәрелүен раслаган һәм электрон гариза бирү датасы күрсәтелгән теркәү номерлы расписка бирелә.

2.11.3. Гариза Бердәм портал, Республика порталы аша юлланса, гариза бирүче запрос бирелгән көнне Бердәм портал, Республика порталындагы шәхси кабинетына һәм электрон почта белән гариза җибәрелүен раслаган, гариза бирү датасы күрсәтелгән теркәү номерлы белдерү ала.

2.11.4. Министрлык дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны әлеге документларның кәгазь версиясен кабат китермичә генә кабул итүне һәм гаризаны регистрацияләүне тәэмин итә.

2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә карата таләпләр

2.12.1. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелү Министрлыкның янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган бинасында һәм бүлмәләрендә башкарыла.

Гариза бирүчеләрне кабул итү урыннарына документлар тутыру өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар урнаштырыла.

Инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтү урынына каршылыксыз керә алуы тәэмин ителә (бинага уңайлы керү-чыгу һәм аның чикләрендә хәрәкәт итү).

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текст форматында һәм мультимедиалы мәгълүмат гариза бирүчегә уңайлы урыннарда урнаштырыла, шул исәптән, инвалидларның мөмкинлекләре чикләнгән булуы да күздә тотыла.

2.12.2. Инвалидларны, шул исәптән, кресло-арба һәм озатып йөрүче эт кулланучыларны, объектларга үтеп керү һәм хезмәт алу мөмкинлеге белән тәэмин итү чаралары гамәлгә ашырыла. Моңа түбәндәгеләр дә керә:

бинага һәм бүлмәләргә, шулай ук, аларда күрсәтелгән хезмәтләргә каршылыксыз үтү шартлары;

министрлык территориясе буйлап мөстәкыйль хәрәкәт итү, миинстрлык бинасына һәм бүлмәләренә керү һәм чыгу мөмкинлеге, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән, кресло-арба кулланып;

күз күреме һәм мөстәкыйль йөри алу функцияләре бозылган инвалидларны озатып йөрү һәм аларга бинада һәм бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;

инвалидларның мөмкинлекләре чикләнгән булуны исәпкә алып, бинага, бүлмәләргә каршылыксыз керә алу һәм хезмәт күрсәтү мөмкинлеге өчен зарури җайланмаларны һәм мәгълүмат чыганакларын уңайлы урыннарда урнаштыру;

дәүләт хезмәте алу өчен зарури тавыш һәм күз күреме аша бирелгән мәгълүматны, шулай ук, язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны Брайль шрифты рельефлы-нокталы билгеләре белән кабатлау, сурдотәрҗемәче, тифлосурдотәрҗемәче кертү;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге № 386н боерыгы белән расланган «Озатучы этнең махсус өйрәтелгәнен раслаучы документ формасын раслау турында, һәм аны бирү тәртипләре» белән күрсәтелгән формада һәм тәртипләрдә махсус өйрәтелгәнлеген раслаучы документ булса, озатучы этне бинага һәм бүлмәләргә кертү;

министрлык хезмәткәрләренең инвалидларга башкалар белән бертигез дәүләт хезмәте алырга комачаулаган каршылыкларны үтәргә ярдәм итүе.

2.12.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларга инвалидлар керүне тәэмин итү таләпләре һәм дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланыла торган чаралар 2016 елның 1 июленнән соң эксплуатациягә кертелгән яки модернизацияләнгән, реконструкцияләнгән биналарга карый.

2.13. Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре

2.13.1. Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) документлар кабул ителә һәм тапшырыла торган биналарының җәмәгать транспортына якын булуы;

2) кирәк кадәр санда белгечләрнең, шулай ук, гариза бирүчеләрнең документларын кабул итә торган урыннарның булуы;

3) мәгълүмати стендларда, министрлыкның рәсми сайтында, Бердәм порталда, Республика порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, сроклары турында тулы мәгълүматның булуы;

4) гаризаны электрон рәвештә тапшыру мөмкинлеге;

5) министрлык бинасын һәм бүлмәләрне инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелгән бүлмәләргә каршылыксыз үтү мөмкинлеге тудыра торган чаралар һәм

җиһазлар белән тәэмин итү, шулай ук, инвалидларга дәүләт хезмәте алуны тәэмин итүче башка шартларны үтәү;

6) министрлык хезмәткәрләренең инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт күрсәтелү өчен бүлмәләргә каршылыксыз үтү белән бәйле булмаган башка киртәләрне үтәргә булышуы.

2.13.2. Дәүләт хезмәтенең сыйфаты күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) документларны кабул итү һәм карау срогының саклануы;

2) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу срогының саклануы;

3) министрлык хезмәткәрләренең әлеге Регламентны бозулары турында нигезле шикаятьләрнең булмавы;

4) Министрлык бинасының, дәүләт хезмәте күрсәтү бүлмәләренең инвалидлар керү өчен уңайлы булуы, дәүләт хезмәтен күрсәтү ачыклыгы күрсәткечләренә ирешү.

5) гариза бирүченең министрлыкның вазыйфаи затлары белән үзара бәйләнешләр саны (консультацияләрне исәпкә алмаганда):

кирәкле документлар белән бергә гариза биргәндә бер тапкыр;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документның кәгазь версиясен алганда бер тапкыр.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә вазыйфаи затлар белән гариза бирүченең аралашу вакытының озынлыгы 15 минуттан артмый.

Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын күчмә радиотелефон элемтәсе җайланмасы ярдәмендә, терминаль җайланмаларны кулланып бәяли ала.

2.13.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турындагы мәгълүматны гариза бирүче Бердәм порталдагы, Республика порталында шәхси кабинет аша, Министрлыкта, МФЦ аша алырга хокуклы.

2.13.4. Дәүләт хезмәте гариза бирүченең яшәү урынына яки фактик торган урынына карамастан, үзе сайлаган теләсә кайсы МФЦда экстерриториаль принцип буенча күрсәтелә.

Гариза бирүче дәүләт хезмәтен комплекслы запрос составында алырга мөмкин.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелүгә бәйле башка таләпләр, шул исәптән:

дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәкләрдә күрсәтү үзенчәлекләрен һәм дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алып;

дәүләт хезмәте күрсәтү турында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә мәгълүмат алу турында.

2.14.1. Зарури һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү таләп ителми.

2.14.2. Гариза бирүче Министрлыкның Дәүләт җирләрен нәтиҗәле файдалану бүлегенә (алга таба – Бүлек) шәхсән үзе, телефон аша һәм (яки) электрон почта аша, почта аша мөрәҗәгать иткәндә консультация бирелә.

2.14.3. Дәүләт хезмәте гариза бирүченең яшәү урынына яки фактик торган урынына карамастан, үзе сайлаган теләсә кайсы МФЦда экстерриториаль принцип буенча күрсәтелә.

2.14.4. Дәүләт хезмәте электрон формада күрсәтелгәндә гариза бирүче түбәндәгеләргә хокуклы:

а) дәүләт хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм портал, Республика порталында урнаштырылган мәгълүматны алу;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган башка документларны, шул исәптән электрон образлары «Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр оештыру турында» № 210-ФЗ Федераль законның 16 статьясының $7^2$ пунктындагы 1 кисәгенә (алга таба - Федераль закон № 210-ФЗ) туры китереп алдарак расланган документлар һәм мәгълүматны Бердәм портал, Республика порталы аша тапшыру;

в) дәүләт хезмәте күрсәтү турында электрон формада бирелгән запросның үтәлеше турында белешмә алу;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын бәяләү;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алу;

е) Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата дәүләт хезмәте күрсәтү органнарының, аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерү процессын тәэмин итүче Республика порталы, федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша шикаять итү.

Гаризаны формалаштыру Бердәм портал, Республика порталында электрон формада запрос тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла, башка төрле формада өстәмә гариза бирү зарурлыгы юк.

2.14.5. Запрос формалаштырганда түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган гариза һәм башка документларны күчерү һәм саклау мөмкинлеге;

2) берничә гариза бирүченең бердәм гариза юллавы күзалланган хезмәтләр буенча мөрәҗәгать иткәндә берничә гариза бирүче тарафыннан запросның бер электрон формасын тутыру мөмкинлеге;

3) гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьгә бастыру мөмкинлеге;

4) гариза бирүченең электрон формага алдарак керткән билгеләрен гариза бирүче теләге белән теләсә кайсы мизгелдә саклау мөмкинлеге, шул исәптән, кертү хаталары киткәндә һәм электрон формага әйләнеп кайтып билгеләрне кабат кертү зарурлыгы туганда;

5) гаризаның электрон форма юлларын ЕСИАга урнаштырылган белешмәне кулланып, Бердәм порталдагы, Республика порталындагы белешмәне кулланып кертә башлаганчы кертә алу, шул исәптән, идентификация һәм аутентификация бердәм системасында булмаган белешмәләргә кагылышлысын да;

6) алдан кертелгән мәгълүматны югалтмыйча электрон форманы тутыруның теләсә кайсы этабына әйләнеп кайту;

7) гариза бирүченең бер ел дәвамында алдан бирелгән запросларга керә алуы, шулай ук, 3 ай дәвамында - өлешчә формалаштырылган запросларга да.

2.14.6. Гариза бирүчеләрнең Министрлыкка, МФЦга кабул ителүгә язылуы (алга таба – язылу) Республика порталы, Министрлык телефоны, МФЦның контакт үзәге аша башкарыла.

Гариза бирүче күпфункцияле үзәкнең кабул итү графигы чикләрендә билгеләнгән теләсә кайсы бу датада һәм вакытта язылу мөмкинлеге бирелә.

Республика порталы аша алдан язылу өчен гариза бирүчегә система сораган мәгълүматны күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилия, исем, этисе исеме (булса);

телефон номеры;

электрон почта адресы (теләге буенча);

кабул ителергә теләгән датасы һәм вакыты.

Алдан язылганда гариза бирүче хәбәр иткән мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматка туры килмәсә, алдан язылу юкка чыгарыла.

Алдан язылганда гариза бирүчегә раслау талонын бастыру мөмкинлеге бирлә. Гариза бирүче электрон почта адресын хәбәр итсә, алдан язылу датасы, вакыты һәм урыны күрсәтелгән мәгълүмат аның почтасына юллана.

Алдан язылганда гариза бирүчегә билгеләнгән вакытка 15 минутка соңга калса, алдан язылган вакыт юкка чыгарылуы турында хәбәр ителә.

Гариза бирүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тарта ала.

Гариза бирүчедән Россия Федерациясе хокукый актларына туры китереп идентификация һәм аутентификация үтүдән, кабул ителү максатын күрсәтүдән тыш, шулай ук, кабул итү өчен кирәкле вакыт интервалын броньлау өчен кирәкле мәгълүматтан башкасын таләп итү тыела.

Алдан язалмау гариза бирүчегә чират тәртибендә мөрәҗәгать итүгә каршы килми.

2.14.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртипләре турында мәгълүмат Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә урнаштырыла.

2.14.8. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә “Бердәм ведомствоара электрон аралашлык системасы” федераль дәүләт мәгълүмат системасы кулланыла.

2.14.9. Бу Регламент физик яки юридик затларга – күчемсез милек объектлары милекчеләренә җир кишәрлекләрен милеккә түләүсез тапшыру, шулай ук, Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен арендага яки милеккә бирү очракларына кагылмый.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы һәм ясалган реестр язуларындагы ялгышларны һәм хаталарны төзәтү өчен кирәкле дәүләт хезмәте күрсәтү вариантларын да кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү вариантлары исемлеге

Дәүләт хезмәте, шулай ук, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы һәм ясалган реестр язуларындагы ялгышларны һәм хаталарны төзәтү бер вариантта башкарыла һәм дәүләт хезмәте күрсәтүнең хезмәт күрсәтү сроклары, гариза бирүчеләр категорияләре, түләү зурлыгы һәм тәртибе, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документлар исемлегенең аерым сценарийләре юк; документлар һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә килеп чыккан юридик гамәлләр аерылмый.

3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документ дубликаты бирү өчен вариантлар исемлеге, шул исәптән, андый дубликат бирүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документ дубликатын бирү бер вариантта башкарыла һәм хезмәт күрсәтү сроклары, гариза бирүчеләр категорияләре, түләү зурлыгы һәм тәртибе, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документлар исемлегенең аерым сценарияләре юк; документлар һәм дубликат бирү нәтиҗәсендә килеп чыккан юридик гамәлләр аерылмый.

Гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документ дубликатын бирүдән баш тарту өчен нигезләр юк.

3.3. Гариза бирүченең профилирование административ процедурасын тасвирлау

Гариза бирүченең профилирование процедурасы гамәлгә ашырылмый.

3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә гамәлләр эзлеклелегенең тасвирламасы.

3.4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация, гариза бирүчегә ярдәм итү, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар тутыру буенча да;

2) гариза бирүче тапшырган документлар комплектын кабул итү һәм карап чыгу;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) ведомствоара запрослар формалаштыру һәм юллау;

4) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору;

5) дәүләт хезмәте күрсәтү турында (күрсәтүдән баш тарту турында) карар кабул итү;

6) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру;

7) дәүләт хезмәте күрсәтелү нәтиҗәсе булган документларда киткән ялгышларны һәм хаталарны төзәтү.

3.5. Гариза бирүчегә консультация, гариза бирүчегә ярдәм итү, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар тутыру буенча да

3.5.1. Административ процедура үтәлә башлауга нигез булып гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелүгә бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгате тора.

Административ процедура үтәлеше өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр):

- МФЦга мөрәҗәгать иткәндә – МФЦ хезмәткәре;

- Министрлыкка мөрәҗәгать иткәндә – Бүлек хезмәткәре.

3.5.2. Гариза бирүче дәүләт хезмәтен алу тәртибе һәм сроклары турында консультацияләр алу өчен МФЦга шәхсән, телефоннан, һәм электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

МФЦ хезмәткәре гариза бирүчегә тапшырыласы документациянең составы, формасы һәм дәүләт хезмәте тутыру өчен кирәкле башка сораулар буенча мәгълүмат бирә.

Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүматны МФЦ сайтына http://mfc16.tatarstan.ru кереп алырга да мөмкин.

Әлеге пункт билгели торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә үтәлә.

Административ процедуралар башкарылу нәтиҗәсе: тапшырылырга тиешле документациянең составы, формасы һәм дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле башка сораулар буенча консультацияләр.

3.5.3. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында, шул исәптән, дәүләт хезмәте алу өчен тапшырыласы документация һәм башка сораулар буенча Министрлыкка шәхсән, телефон аша һәм (яки) электрон почта, почта аша мөрәҗәгать итеп, шулай ук, Бердәм портал, Республика порталы, Министрлык сайтында консультация алырга мөмкин.

3.5.4. Министрлык хезмәткәре гариза бирүчене дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе, Министрлыкның урнашкан урыны, белешмә телефоннары, эш сәгатьләре, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гаризалар кабул итү графигы турында мәгълүмат бирә һәм гариза бирүчегә ярдәм итә, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны формалаштыру буенча да.

Әлеге пункт билгели торган процедуралар мөрәҗәгать кергән көндә үтәлә.

Административ процедуралар башкарылу нәтиҗәсе: тапшырылырга тиешле документациянең составы, формасы һәм дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле башка сораулар буенча консультацияләр.

3.6. Гариза бирүче тапшырган документлар комплектын кабул итү һәм карап чыгу

3.6.1. Гариза бирүче дәүләт хезмәте алу өчен МФЦга мөрәҗәгать итергә хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтү экстерриториаль принцип буенча яшәү урынына яисә фактик яшәгән (торган) карамастан, гариза бирүче сайлап алган теләсә кайсы МФЦда башкарыла. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен әлеге Регламентның 2.6.1, 2.6.2.1, 2.6.2.2,

2.6.2.3 пунктларында күрсәтелгән документларны МФЦ аша кабул итү тиешле тәртиптә кабул ителгән МФЦ Регламентына һәм Килешүгә туры китереп башкарыла.

Техник мөмкинелекләр булганда кирәкле документлар электрон рәвештә (документларның ЭЦП МФЦда имзаланган скан-образлары) МФЦның мәгълүмати системасы аша тапшырыла. Бу очракта документлар Министрлыкка Килешүдә күрсәтелгән даимилек белән җибәрелә.

Гариза һәм документларны гариза бирүченең вәкиле тапшыра ала.

3.6.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар Бердәм портал, Республика порталы аша электрон формада кабул ителә.

3.6.2.1. Бүлек белгече гариза Бердәм портал, Республика порталы аша бирелгәндә 1 эш көне эчендә, гариза ял яки бәйрәм көнендә керсә – беренче эш көнендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итә.

Гариза керүе турында электрон хәбәр һәм гаризаның регистрацияләнүе турында белдерү Бердәм портал, Республика порталындагы шәхси кабинетта үтенеч язуы каралу статусында автомат рәвештә чагыла.

3.6.2.2. Гариза бирүче Бердәм портал, Республика порталы аша электрон формада гариза бирү өчен түбәндәге гамәлләрне кыла:

Бердәм портал, Республика порталында авторизация үтә;

Бердәм портал, Республика порталында электрон гариза формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри белешмәләр кертелә торган электрон гариза формасын тутыра;

электрон гариза формасына электрон рәвештәге документларны яки документларның электрон образларын беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм ризалашу фактын раслый (электрон гариза формасына ризалык турында тиешле билгене куя);

хәбәр ителгән мәгълүматларның дөреслеген раслый (электрон гариза формасына тиешле билгене куя);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза формасында тиешле төймәгә баса);

электрон гариза әлеге Регламентның 2.6.5 пункты таләпләренә туры китереп имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Регламентның әлеге пункты белән билгеләнгән процедура гариза бирүче

мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Административ процедуралар башкарылу нәтиҗәсе: электрон арадашлык системасы ярдәмендә Министрлыкка җибәрелгән электрон эш.

Формалаштырылган запросны формат һәм логик яктан тикшерү гариза бирүче запросның электрон формасындагы һәр юлны тутырганнан соң Бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә башкарыла. Бердәм портал запросның электрон формасындагы юлының дөрес тутырылмавын ачыкласа, гариза бирүчегә запросның электрон формасы өстендә үк мәгълүмати хәбәр буларак, ачыкланган ялгыш һәм аны төзәтү тәртибе турында белдерелә.

3.6.2.3. Бүлек белгече Бердәм портал, Республика порталыннан килгән электрон гаризаларның барлыгын тикшерә, көнгә ике тапкырдан да ким булмаган вакытта кергән гаризаларны һәм беркетелгән документларның электрон образларын (документларны) карап чыга.

Эш номенклатурасына туры китереп гаризага номер һәм «Документларны тикшерү» статусы бирә, Бердәм портал, Республика порталының шәхси кабинетында автомат рәвештә чагыла.

Бүлек белгече карау өчен документлар кергәч:

электрон формада кергән эшләрне, шул исәптән гариза бирүче беркеткән электрон рәвешле документларны һәм документларның электрон образларын карап чыга;

документларның электрон образларының комплектлылыгын, укылышын тикшерә;

Бердәм порталга, Республика порталына мөрәҗәгать итеп электрон имзаның гамәлдә булу шартларының саклануын тикшерә (гариза бирүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган документларның электрон образлары бирелгән очракта).

электрон эшләрне, шул исәптән, гариза бирүче беркеткән электрон формаларын һәм документларның электрон образларын карап чыга, документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7.1 пунктында күрсәтелгән нигезләрнең булу-булмавын, гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны кире кайтару өчен әлеге Регламентның 2.7.2 пунктында күрсәтелгән нигезләрнең булу-булмавын тикшерә.

Бүлек белгече документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7.1 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта гариза бирүченең Республика порталындагы шәхси кабинетына гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны кабул

итүдән баш тарту турында баш тарту сәбәбе күрсәтелгән белдерү юллый.

Бүлек белгече документларны кайтару өчен әлеге Регламентның 2.7.2 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта гариза бирелгәннән ун көннән дә соңга калмыйча гариза бирүченең Республика порталындагы шәхси кабинетына гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны карамыйча кайтару турында кайтару сәбәбе күрсәтелгән белдерү юллый.

Әлеге Регламентның 2.7.1 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булмаса, гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны кире кайтару өчен әлеге Регламентның 2.7.2 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаса, Бүлек белгече документлар кабул ителгән көнне “Ведомствоара мәгълүмати арадашлык” административ процедурасын башкарырга керешә.

Административ процедуралар башкаруның нәтиҗәсе: карау өчен кабул ителгән документлар комплекты яки сәбәпләре күрсәтелеп гариза бирүчегә кайтарылган гариза һәм аңа беркетелгән документлар комплекты.

3.6.2.4. Әлеге Регламентның 3.6.2.3 пунктында күрсәтелгән процедураларны башкару, техник мөмкинлекләр булганда, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен тәгаенләнгән автоматлаштырылган мәгълүмати системаны кулланып, автоматик режимда башкарыла.

3.6.3. Министрлыкка документлар формада гариза бирүчедән кергән документлар комплектын карап чыгу.

Контроль бүлеге белгече Бүлек белгече катнашында кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7.1 пунктында күрсәтелгән нигезләрнең булу-булмавын, гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны кире кайтару өчен әлеге Регламентның 2.7.2 пунктында күрсәтелгән нигезләрнең булу-булмавын тикшереп чыга.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7.1 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаса, гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны кире кайтару өчен әлеге Регламентның 2.7.2 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаса, гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны регистрацияли һәм карау өчен Бүлеккә юллый.

Кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7.1 пунктында күрсәтелгән нигезләр булса, гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны кире кайтару өчен әлеге Регламентның 2.7.2 пунктында күрсәтелгән нигезләр булса, Бүлек белгече гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны регистрацияләмичә һәм Бүлек белгече әзерләгән аңлатма буенча телдән генә документларны кабул итүдән баш тарту өчен

(гаризаны һәм аңа беркетелгән документларын кире кайтару нигезләре) ачыкланган сәбәпләрне аңлатып гариза бирүчегә кайтара.

Гариза бирүче документларның расланмаган күчермәләрен тапшырган очракта, Бүлек белгече оригиналга карап документларның күчермәләрен чагыштыра һәм үз имзасы белән раслый.

Әлеге регламентның 3.6.3 пункты билгеләгән процедуралар гариза һәм документлар кергән көндә гамәлгә ашырыла.

Административ процедуралар башкаруның нәтиҗәсе: карау өчен кабул ителгән документлар комплекты яки документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләр турында телдән аңлату, гариза бирүчегә кайтарылган гариза һәм аңа беркетелгән документлар.

3.6.4. Документлар Министрлыкка почта аша документлар формасында кергән очракта контроль бүлеге хезмәткәре Бүлек белгече катнашында кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7.1 пунктында күрсәтелгән нигезләрнең булу-булмавын, гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны кире кайтару өчен әлеге Регламентның 2.7.2 пунктында күрсәтелгән нигезләрнең булу-булмавын тикшереп чыга.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7.1 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаса, гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны кире кайтару өчен әлеге Регламентның 2.7.2 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаса, Контроль бүлеге белгече гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны регистрацияли һәм карау өчен Бүлеккә юллый.

Бүлек белгече документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7.1 пунктында күрсәтелгән нигезләр булса, гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны кире кайтару өчен әлеге Регламентның 2.7.2 пунктында күрсәтелгән нигезләр булса, гариза бирелгәннән ун көннән дә соңга калмыйча гариза бирүчегә гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны кайтару турында кайтару сәбәбе күрсәтелгән белдерү юллый.

Административ процедуралар башкаруның нәтиҗәсе: карау өчен кабул ителгән яки сәбәпләре күрсәтелеп гариза бирүчегә кайтарылган документлар комплекты.

3.7. Ведомствоара запрослар формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашкан органнарга юллау

3.7.1. Запрос җибәрү өчен нигез булып гариза бирүченең регистрацияләнгән гаризасы тора.

3.7.2. Бүлек белгече гаризаны һәм документларны контроль бүлегеннән алганнан соң “Гаризаның ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында үтү бите” тутыра (әлеге Регламентка 6 нчы кушымта) һәм ведомствоара электрон арадашлык системасы аша электрон формада (шул исәптән, бердәм ведомствоара электрон арадашлык системасын кулланып) әлеге Регламентның 2.6.6 пункты белән каралган документларны һәм мәгълүматны бирү турында запрослар юллый.

3.7.2.1. Җир кишәрлеген сатулашулар уздырмыйча милеккә, арендага бирү өчен кирәк булган документлар исемлеге:

1) соралган җир кишәрлеге турында ЕГРНнан өземтә. Запрос “ТР ФКП” ФБУга юллана;

2) Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан гариза бирүче булган юридик зат турында яисә Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан гариза бирүче булган шәхси эшмәкәр турында өземтә. Запрос ТР буенча ФСХИга юллана;

3) инвалидлык турында белешмә (инвалидлык төркемен күрсәтеп, инвалидлык билгеләнүен раслаучы белешмә; инвалидны, инвалид баланы реабилитацияләү яки абилитацияләүнең индивидуаль программасы), мәгълүмат «Инвалидларның Федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмати системасында (ФГИС ФРИ) була, гражданин (торакны яллаучы) инвалид булса яки аның гаиләсе составында инвалид булса. Запрос РФ ФПССка юллана

4) гариза бирүченең җир кишәрлеген сатулашулар уздырмыйча алу хокукын раслаган Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең «Гариза бирүченең җир кишәрлеген сатулашулар уздырмыйча алу хокукын раслаучы документларны раслау турында» 2020 елның 2 сентябрендәге № П/0321 Боерык белән расланган документлар исемлегендә каралган башка документлар һәм белешмәләр. Дәүләт хакимиятенең вәкаләтле федераль органына, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органына, җирле үзидарә органына юллана.

3.7.2.2. Җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында бирү өчен кирәк булган документлар исемлеге:

1) соралган җир кишәрлеге турында ЕГРНнан өземтә. Запрос ТР ФКПга юллана.

2) гариза бирүче булган юридик зат турында ЕГРЮЛдан өземтә. ТР буенча ФСХИга юллана.

3.7.2.3. Җир кишәрлеген түләүсез файдалану хокукында бирү өчен кирәк булган документлар исемлеге:

1) соралган җир кишәрлеге турында ЕГРНнан өземтә. Запрос ТР ФКПга юллана.

2) күчемсез милек объекты турында (соралган җир кишәрлегендә урнашкан бина һәм (яки) корылмалар турында) ЕГРН өземтәсе. ТР ФКПга юллана.

3) гариза бирүче булган юридик зат турында ЕГРЮЛдан өземтә. Запрос ТР ФСХИга юллана.

4) коммерциячел булмаган оешма төзү турында карар күчермәсе – җир кишәрлеген аерым категория гражданнарны торак белән тәэмин итү өчен торак төзелеше максатларында Татарстан Республикасы законнарында каралган һәм Татарстан Республикасында төзелгән коммерциячел булмаган оешмага биргән очракта. Запрос Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органына юллана.

5) күчемсез милек объекты турында (соралган җир кишәрлегендә урнашкан биналар, корылмалар турында) ЕГРН өземтәсе (бина, корылма төзелгән очракта кирәкми) – җир кишәрлеген дини яки хәйрия билгеләнешендәге биналар, корылмалар төзү өчен дини оешмага биргәндә. Запрос ТР ФКПга юллана.

6) РФ ХКның 66[1] статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган хезмәт эшчәнлеге турында белешмә. Запрос (2020 елның 1 гыйнварыннан соңгы чор өчен) Россия Федерациясе РФ ФПССка яки гариза бирүченең соңгы эш урыны буенча эш бирүчегә (гражданнар өчен) юллана.

3.7.2.4. Ведомствоара мәгълүмати запрослар әлеге Регламентның 3.7.2.1 – 3.7.2.3 пунктлары нигезендә гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатыннан күрсәтелгән органнарга юллана.

Әлеге Регламентның 3.7.2.1 – 3.7.2.3 пунктлары белән билгеләнгән процедуралар гариза һәм документлар кергән көнне үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: мәгълүмат (документлар) бирү турындагы запрослар.

3.7.2.5. Ведомствоара запрослар буенча әлеге Регламентның 2.6.6 пункты белән каралган документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) алар сакланган органнардан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кагыйдәләрен, шул исәптән, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яки) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне оештыруның киңәш ителгән кагыйдәләрен раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия

Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләрен көчен югалткан дип тану турында" 2021 елның 23 июнендәге № 963 карары нигезендә тиешле запрос җибәрелгәннән соң 48 сәгатьтән дә соңга калмаган вакыт эчендә электрон рәвештә бирелә.

3.7.2.6. Ведомствоара мәгълүмати запрослар кәгазь рәвештә дә бирелә ала:

1) ведомствоара мәгълүмати запросларда соралган белешмәләр электрон формада булмаса, электрон формада бирелү мөмкин түгел;

2) ведомствоара запрос юллаганда документларның төп нөсхәсенең кәгазьдә бирелү ихтыяҗы булганда. Ведомоствоара хезмәттәшлек кәгазьдә бирелсә, әлеге Регламентның 2.6.6 пунктында күрсәтелгән документларны (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) әлеге документлар үз карамагында булган органнар бирә.

№ 210-ФЗ Федераль законның $7^2$ статьясының 3 кисәге нигезендә ведомствоара запросларга җавап әзерләү һәм җибәрү срогы ведомоствоара запрос кергәннән соң биш эш көненнән арта алмый (ике эш көне – дәүләт кадастр учеты һәм (яки) күчемсез милек объектларына хокукларны дәүләт регистрациясе).

Административ процедураның нәтиҗәсе: Бүлек белгеченең соралган документларны (күчермәләре яки аларда булган белешмәләр), яки баш тарту турында хәбәрне алуы.

Белешмәләрне файдалануның максаты гариза бирүче тапшырган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук, законнар һәм гариза бирүченең хокукларын бозуга юл куймый торган карар кабул итү.

3.7.4. Министрлыкның структур бүлекчәләре арасында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм Министрлык карамагында булган мәгълүматны алмашу, шул исәптән, электрон формада, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Эш башкару буенча инструкция нигезендә алып барыла.

3.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору.

Законнарда дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

3.9. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында (хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында) карар кабул итү

3.9.1. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсен әзерләгәндә җир кишәрлеген сату-алу шартнамәсе проекты, арендага бирү шартнамәсе проекты (алга таба – сату-алу шартнамәсе, аренда шартнамәсе проекты), яисә җир кишәрлеген түләүсез файдалану шартнамәсе проекты (алга таба – түләүсез файдалану шартнамәсе проекты) әзерләү,

шулай ук, күрсәтелгән шартнамә проектларын гариза бирүчегә юллау гамәлгә ашырыла, җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирү турында карар проекты (алга таба – җир кишәрлеген бирү турында карар), яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты (җир кишәрлеген сатулашулар уздырмыйча милеккә бирүдән баш тарту турында карар, җир кишәрлеген сатулашулар уздырмыйча арендага бирүдән баш тарту турында карар, җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирүдән баш тарту турында карар, җир кишәрлеген түләүсез файдалануга бирүдән баш тарту турында карар (алга таба – баш тарту турында карар) әзерләү гамәлгә ашырыла.

3.9.2. Административ процедураларны башлау өчен ведомствоара арадашлык органнары белгечләреннән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар комплектының (белешмәләрнең) керүе нигез булып тора.

3.9.3. Бүлек белгече әлеге Регламентның 3.7.2.1 – 3.7.2.3 пунктларына таянып соратып алынган белешмәләр (документлар) кергәч түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарта торган әлеге Регламентның 2.8.2 пунктында күрсәтелгән нигезләр булу-булмавын тикшерә (әлеге Регламентка 5 нче кушымта);

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү (арендага бирү шартнамәсе яки сату-алу шартнамәсе проекты, яисә түләүсез файдалану шартнамәсе проекты, җир кишәрлеген бирү турында карар проекты яки баш тарту турында карар проекты);

җир кишәрлеген бирү турында карар проектын һәм сату-алу шартнамәсе проектын, яки аренда шартнамәсе проектын, яки түләүсез файдалану шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карар проектын килештерү өчен Бүлек мөдиренә юллау.

Әлеге Регламентның 2.8.2 пунктында күрсәтелгән шартларның берсе генә булса да, Бүлек белгече баш тарту турында карар проекты әзерли.

Гариза бирүче гаризаны һәм документларын электрон рәвештә Республика порталы аша җибәргән булса һәм гаризада дәүләт хезмәте нәтиҗәсен электрон рәвештә алу күрсәтелгән булса, Бүлек белгече җир кишәрлеген бирү турында карар проектын һәм сату-алу шартнамәсе проектын, яки аренда шартнамәсе проектын, яки түләүсез файдалану шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карар проектын электрон рәвештә әзерли.

Әлеге пункт билгели торган процедура юлланган запросларга җавап алынганнан соң бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: Килештерү өчен Бүлек мөдиренә юлланган җир кишәрлеген бирү турында карар проектын һәм сату-алу шартнамәсе проектын, яки аренда шартнамәсе проектын, яки түләүсез файдалану шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карар проекты.

3.9.4 Бүлек мөдире җир кишәрлеген бирү турында карар проектын һәм сату-алу шартнамәсе проектын, яки аренда шартнамәсе проектын, яки түләүсез файдалану шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карар проектын карап чыга һәм килештерү өчен Җир ресурслары идарәсе (алга таба – Идарә) башлыгына җибәрә.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек мөдире белән килештерелгән һәм килештерү өчен Идарә башлыгына җибәрелгән җир кишәрлеген бирү турында карар проекты һәм сату-алу шартнамәсе проекты, яки аренда шартнамәсе проекты, яки түләүсез файдалану шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар проекты.

3.9.5. Идарә башлыгы җир кишәрлеген бирү турында карар проектын һәм сату-алу шартнамәсе проектын, яки аренда шартнамәсе проектын, яки түләүсез файдалану шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карар проектын карап чыга, килештерә һәм Бүлек белгеченә җибәрә.

3.9.4, 3.9.5 пунктлар белән билгеләнә торган процедуралар, аннан алдагы процедура беткәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек мөдире, Идарә башлыгы белән килештерелгән җир кишәрлеген бирү турында карар проекты һәм сату-алу шартнамәсе проекты, яки аренда шартнамәсе проекты, яки түләүсез файдалану шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар проекты.

3.9.6. Бүлек белгече Бүлек мөдире һәм Идарә башлыгы белән килештерелгән җир кишәрлеген бирү турында карар проектын һәм сату-алу шартнамәсе проектын, яки аренда шартнамәсе проектын, яки түләүсез файдалану шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карар проектын хокукый экспертиза үткәрү өчен Хокук идарәсенә юллый.

Әлеге пункт билгеләгән процедура алдагы тәмамланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек мөдире һәм Идарә башлыгы белән килештерелгән һәм Хокук идарәсенә юлланган җир кишәрлеген бирү турында карар проекты һәм сату-алу шартнамәсе проекты, яки аренда шартнамәсе проекты, яки түләүсез файдалану шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар проекты.

3.9.7. Хокук идарәсе белгече җир кишәрлеген бирү турында карар проектына һәм сату-алу шартнамәсе проектына, яки аренда шартнамәсе проектына, яки түләүсез файдалану шартнамәсе проектына яисә баш тарту турында карар проектына хокукый экспертиза ясый һәм хокук идарәсе башлыгына килештерелгән проектларны килештерү өчен яисә әлеге проектларда кимчелекләр булган очракта хокук идарәсе бәяләмәсе проектын имзалау өчен юллый.

Процедура нәтиҗәсе: Җир кишәрлеген бирү турында карар проектында һәм сату-алу шартнамәсе проектында, яки аренда шартнамәсе проектында, яки түләүсез файдалану шартнамәсе проектында яисә баш тарту турында карар проектында кимчелекләр булган очракта килештерү өчен хокук идарәсе башлыгына юлланган хокук идарәсе бәяләмәсе проекты яки килештерелгән җир кишәрлеген бирү турында карар проекты һәм сату-алу шартнамәсе проекты, яки аренда шартнамәсе проекты, яки түләүсез файдалану шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар проекты.

3.9.8. Хокук идарәсе башлыгы җир кишәрлеген бирү турында карар проекты һәм сату-алу шартнамәсе проекты, яки аренда шартнамәсе проекты, яки түләүсез файдалану шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар проекты буенча хокук идарәсе бәяләмәсе проектын имзалый яки җир кишәрлеген бирү турында карар проектын һәм сату-алу шартнамәсе проектын, яки аренда шартнамәсе проектын, яки түләүсез файдалану шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карар проектын килештерә һәм Бүлек белгеченә юллый.

3.9.7, 3.9.8 пунктлар билгели торган процедура, әлеге Регламентның 3.9.6 пункты белән каралган процедура беткәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Җир кишәрлеген бирү турында карар проекты һәм сату-алу шартнамәсе проекты, яки аренда шартнамәсе проекты, яки түләүсез файдалану шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар проекты буенча хокук идарәсе бәяләмәсе яки килештерелгән җир кишәрлеген бирү турында карар проекты һәм сату-алу шартнамәсе проекты, яки аренда шартнамәсе проекты, яки түләүсез файдалану шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар проекты.

3.9.9. Бүлек белгече хокук идарәсе бәяләмәсен алган очракта булган кимчелекләрне төзәтә һәм җир кишәрлеген бирү турында карар проектын һәм сату-алу шартнамәсе проектын, яки аренда шартнамәсе проектын, яки түләүсез файдалану шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карар проектын килештерү өчен хокук идарәсе башлыгына юллый.

Процедуралар нәтиҗәсе: Килештерү өчен хокук идарәсе башлыгына юлланган хокук идарәсе киңәше буенча төзәтелгән җир кишәрлеген бирү турында карар проекты һәм сату-алу шартнамәсе проекты, яки аренда шартнамәсе проекты, яки түләүсез файдалану шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар проекты.

3.9.10. Хокук идарәсе башлыгы хокук идарәсе бәяләмәсендә күрсәтелгән кимчелекләрнең төзәтелү фактын тикшереп чыга һәм тиешле проектны килештерә.

3.9.9 һәм 3.9.10 пунктларда билгеләнгән процедуралар алдагы процедурадан соң бер эш көне эчендә, әлеге Регламентның 3.9.7, 3.9.8 пунктлары белән каралган процедуралар тәмамлангач гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Хокук идарәсе башлыгы белән килештерелгән һәм Бүлек белгеченә юлланган җир кишәрлеген бирү турында карар проекты һәм сату-алу шартнамәсе проекты, яки аренда шартнамәсе проекты, яки түләүсез файдалану шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар проекты.

3.9.11. Бүлек белгече хокук идарәсе башлыгы белән килештерелгән җир кишәрлеген бирү турында карар проектын, аренда шартнамәсе проектын, түләүсез файдалану шартнамәсе проектын яки баш тарту турында карар проектын – кул куярга, сату-алу шартнамәсе проектын – килештерү өчен министрның беренче урынбасарына юллый.

Әлеге пункт билгеләгән процедура алдагы процедура тәмамланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Министрның беренче урынбасарына имза кую өчен юлланган җир кишәрлеген бирү турында карар проекты, аренда шартнамәсе проекты, түләүсез файдалану шартнамәсе проекты яки баш тарту турында карар проекты, министрның беренче урынбасарына килештерү өчен юлланган сату-алу шартнамәсе проекты.

3.9.12. Министрның беренче урынбасары җир кишәрлеген бирү турында карар проектын, аренда шартнамәсе проектын, түләүсез файдалану шартнамәсе проектын яки баш тарту турында карар проектын имзалый һәм теркәү өчен эш башкару бүлегенә җибәрә яисә сату-алу шартнамәсе проекты һәм аңа кушып җибәрелә торган хатны килештерә һәм имза кую өчен министрга юллый.

Гаризада хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон рәвештә алу күрсәтелгән очракта, министрның беренче урынбасары җир кишәрлеген бирү турында карарга яки аренда шартнамәсе проектына, түләүсез файдалану шартнамәсе проектына яки баш тарту турында карарга электрон документ формасында көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куя.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: Министрның беренче урынбасары имзалаган һәм регистрацияләү өчен эш башкару бүлегенә җибәрелгән җир кишәрлеген бирү турында карар, аренда шартнамәсе проекты, түләүсез файдалану шартнамәсе проекты проекты, яки баш тарту турында карар яисә кул кую өчен министрга юлланган сату-алу шартнамәсе проекты һәм аңа кушып җибәрелә торган хат.

3.9.13. Министр сату-алу шартнамәсе проекты һәм аңа кушып җибәрелә торган хатны имзалый һәм регистрациягә контроль бүлегенә юллый.

Гаризада хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон рәвештә алу күрсәтелгән очракта, Министр сату-алу шартнамәсе проектына һәм аңа кушып җибәрелә торган хатка электрон документ формасында көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куя.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: Министр кул куйнан һәм регистрациягә контроль бүлегенә юллаган сату-алу шартнамәсе проекты һәм аңа кушып җибәрелә торган хат.

3.9.14. Әлеге Регламентның 3.9.3 – 3.9.13 пунктларында күрсәтелгән аерым процедуралар техник мөмкинлекләр булганда дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүөчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмати системаны кулланып, автомат режимда башкарыла.

3.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру

3.10.1. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе гариза бирүчегә үзе сайланган ысул белән бирелә (җибәрелә):

гариза бирүченең үз кулына Министрлыкта язмача яки гариза бирүче яшәгән яки торган урынга почта аша; электрон почта һәм (яки) Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинетка электрон документ формасында;

гариза бирүченең теләге буенча дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе МФЦ аша МФЦ регламентына туры китереп, Министрлыктан җибәрелгән электрон документ экземпляры формасында алыныргa мөмкин, документ кәгазьгә чыгарылып, МФЦ мөһере басыла һәм МФЦ хезмәткәре имзасы куела.

3.10.2. Административ процедураны башлау өчен нигез булып контроль бүлеге белгеченең дәүләт хезмәте күрсәтүне раслаган документны (җир кишәрлеген бирү турында карар, сату-алу шартнамәсе, аренда шартнамәсе, түләүсез файдалану шартнамәсе) яисә баш тарту турында карарны алуы тора.

Контроль бүлеге белгече дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә регистрация үткәрә.

Бүлек белгече:

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турындагы мәгълүматны дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмати системасының документацияләр алып бару подсистемасына кертә;

гариза бирүчене (аның вәкилен) Бердәм портал, Республика порталы аша электрон арадашлык юлы белән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен МФЦдан алу мөмкинлеге турында хәбәр итә.

Процедуралар техник мөмкинлек булганда дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмати системасыны кулланып автомат режимда башкарыла.

Әлеге пункт билгели торган процедуралар дәүләт хезмәте күрсәтүне (күрсәтүдән баш тартуны) раслаган документка имза куелган көндә үтәлә.

Административ процедуралар башкарылу нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында мәгълүматны мәгълүмат системаларына урнаштыру, гариза бирүчегә (аның вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе һәм аны алу ысуллары турында хәбәр итү.

3.10.3. Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алырга МФЦга мөрәҗәгать итсә, МФЦ хезмәткәре гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документның кәгазь экземпляры рәвешендә тапшыра. Гариза бирүче соравы буенча электрон документның кәгазь экземпляры белән бергә электрон документның экземпляры күчергечкә яздырып бирелергә мөмкин.

Бу пункт билгели торган процедуралар МФЦның эш регламенты белән билгеләнгән срокларда гариза бирүче килгәч чират тәртибендә башкарыла.

3.10.4. Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алырга Бердәм портал, Республика порталы ашы мөрәҗәгать итсә, шәхси кабинетка автомат рәвештә министрның яки министрның беренче урынбасарының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы куелган дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документның электрон образы җибәрелә.

Бу пункт билгели торган процедуралар дәүләт хезмәте күрсәтүне раслаган (хезмәт күрсәтүдән баш тарткан) документка министрның беренче урынбасары, министр кул куйган көнне башкарыла.

Административ процедуралар башкарылу нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүне раслаган документны яки, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуны, Бердәм портал, Республика порталын кулланып гариза бирүчегә җибәрү (тапшыру).

3.10.5. Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алырга килгән очракта, контроль бүлегенең документларны бирүгә җаваплы белгече түбәндәгеләрне башкара:

гариза бирүченең шәхесен ачыклый, шәхесен раслаган документны тикшерә;

вәкилнең вәкаләтләрен тикшерә (боерык, ышанычнамә һ.б.);

гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен бирә һәм исәп-хисап кенәгәсенә документлар тапшырылу турында язып куя;

кушып бирелә торган хатны тапшыра.

Әлеге пункт билгели торган процедура гариза бирүче килгән көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе (җир кишәрлеге бирү турында карар, сату-алу шартнамәсе, аренда шартнамәсе, түләүсез файдалану шартнамәсе яки баш тарту турында карар).

3.10.6. Гариза бирүче алган көннән соң утыз календарь көне эчендә сату-алу шартнамәсен, аренда шартнамәсен, түләүсез файдалану шартнамәсен имзалый һәм Министрлыкка тапшыра.

3.10.7. Министрның беренче урынбасары һәм гариза бирүче имза куйган җир кишәрлеген сату-алу, аренда, түләүсез файдалану шартнамәсе Министрлыкның Исәпләү, мониторинг һәм мәгълүмати хезмәттәшлек идарәсенең Татарстан Республикасының дәүләт милке реестры бүлегендә (алга таба – реестр бүлеге) регистрацияләнә һәм гариза бирүчегә юллана.

Бу пункт билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң ике эш көне эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: регистрацияләнгән һәм гариза бирүчегә юлланган җир кишәрлеген сату-алу, арендалау, җир кишәрлеген түләүсез файдалану шартнамәсе.

3.11. Гариза бирүчедән өстәмә мәгълүмат алу

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышында гариза бирүчедән нинди дә булса өстәмә документлар һәм (яисә) мәгълүмат алу каралмаган.

3.12. Дәүләт хезмәте күрсәтелү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы ялгыш язуларны һәм хаталарны (алга таба – техник хата) төзәтү:

3.12.1. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында карарда яисә җир кишәрлеген сату-алу шартнамәсе, аренда шартнамәсе, җир кишәрлеген түләүсез

файдалану шартнамәсендә техник хатаны төзәтү буенча мөрәҗәгате техник хатаның төзәтелүенә нигез булып тора.

Техник хата электрон формада һәм МФЦ аша төзәтелми.

3.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта техник хата табылганда гариза бирүче түбәндәгеләрне Министрлыкка юллый:

техник хатаны төзәтү турында гариза (әлеге Регламентка 7 нче кушымта);

гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак тапшырылган, техник хата булган документ;

техник хатаның булуын дәлилләгән юридик көчкә ия документлар.

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак тапшырылган документтагы мәгълүматта булган техник хатаны төзәтү турында гариза гариза бирүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән яки почта аша тапшырыла.

3.12.3. Контроль бүлеге белгече беркетелгән документлары белән бергә техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итеп ала да, регистрацияләп Бүлек белгеченә бирә.

Әлеге пункт билгеләгән процедуралар гариза регистрацияләнгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм рәсмиләштерелгән гаризаның карау өчен Бүлек белгеченә юллануы.

3.12.4. Бүлек белгече документларны карый да, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтүләр кертү максатыннан әлеге Регламентның 3.6, 3.9 пунктларында каралган процедураларны гамәлгә ашыра, гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкиленә) имза куйдырып шәхсән үзенә төзәтелгән документны тапшыра, гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хата булган төп нөсхәне ала, яки гариза бирүче адресына почта аша (электрон почта аша) Министрлыкка техник хата булган документның төп нөсхәсен китереп документны алу мөмкинлеге турында хат юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура техник хата табылганнан соң яки теләсә кайсы катнашы булган затның хата турындагы мөрәҗәгатеннән соң ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: яңадан формалаштырылган, гариза бирүчегә тапшырылган (юлланган) документ.

3.13. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча документ дубликатын бирү

3.13.1. Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документны бозса яки югалтса, Министрлыкка документның дубликатын сорап мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Министрлыкка дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документның дубликатын бирү турында министр исеменә ирекле формада дубликат бирү сәбәпләрен күрсәтеп язылган гариза керү дубликатны бирү процедурасын башлау өчен нигез булып тора.

Дубликат электрон формада һәм МФЦ аша бирелми.

3.13.2. Министрлыкка кергән гариза регистрация өчен җаваплы Министрлыкның контроль бүлеге хезмәткәре тарафыннан кергән көнне регистрацияләнә һәм бер эш көнендә карап чыгу өчен министрның беренче урынбасарына тапшырыла.

Министрның беренче урынбасары гаризаны бер эш көне эчендә карап чыга һәм башкару өчен Бүлек мөдиренә бирә. Бүлек хезмәткәре ике эш көне эчендә шул ук регистрация номеры һәм датасы белән документның дубликатын әзерли, өстәге почмагына «ДУБЛИКАТ» дип языла, документның әзер дубликаты имза белән гариза бирүченең кулына тапшырыла яки гариза бирүче күрсәткән адрес буенча белдерүле заказлы хат белән почта аша юллана.

Процедураның нәтиҗәсе булып дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документның дубликаты тора.

## 4. Администатив регламентның үтәлешен контрольдә тоту формалары

4.1. Җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан регламент нигезләмәләренең һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр куючы башка норматив хокукый актларның үтәлешен һәм башкарылуын, шулай ук, алар кабул иткән карарларны дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Идарә (бүлек) җитәкчеләре әлеге Регламент нигезләмәләрен үтәү һәм башкаруны тикшерү юлы белән контрольдә тота.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне Министрлыкның вазыйфаи затлары контрольдә тота. Контрольдә тотучы вазыйфаи затларның вәкаләтләре Министрлык идарәләре (бүлекләре) турында нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

4.3. Агымдагы контроль Министрлыкның вазыйфаи затларының әлеге Регламент нигезләмәләрен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгеләүче башка норматив хокукый актларның үтәвен тикшереп тору юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы контроль даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту тикшерүләр үткәрүне, гариза бирүчеләрнең дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затларның кылган (кылмаган) гамәлләре турында шикаятьләр булган мөрәҗәгатьләрен карап, карарлар кабул итүне һәм гариза бирүченең мөрәҗәгатенә җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып түбәндәгеләр тора:

канцелярия эшләрен алып бару;

документлар карау нәтиҗәләренең закон таләпләренә (әлеге Регламентка) туры килүе;

документлар кабул итү срокларын һәм тәртибен саклау;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләрне тапшыру срогы һәм тәртибе саклану.

Тикшерүләр үткәрү планлы (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш (гариза бирүченең мөрәҗәгате буенча) булырга мөмкин.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү буенча планнан тыш тикшерү карары түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Регламент таләпләрен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актларны бозу очраклары алдарак ачыкланып, аларның төзәтелүен тикшерү өчен;

2) Министрлыкның дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затларының үз гамәлләре белән (гамәл кылмаулары белән) аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозулары турында гариза бирүчеләрнең зарланып мөрәҗәгать итү очрагында.

4.6. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозулар ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан контрольдә тоту Министрлык эшчәнлегенең дәүләт хезмәте күрсәтүдәге ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтү күпфункцияле үзәгенең, № 210-ФЗ Федераль законның 16 статьясының $1^1$ кисәгендә

күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук, аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерү тәртибе

5.1. Гариза бирүчеләр Министрлыкның, Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата Министрлыкка шикаять белдерә ала.

Министрның дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә

МФЦ хезмәткәренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата шикаять МФЦ җитәкчесенә бирелә.

МФЦның кылган (кылмаган) гамәлләренә карата шикаять МФЦны гамәлгә куючыга ( (алга таба – МФЦны гамәлгә куючы) бирелә.

5.2. Гариза бирүче түбәндәге очракларда да шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирүченең запросын теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылганда;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар яки мәгълүмат, яки гамәлләр кылуны таләп иткәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр баш тартуга нигезләр федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә күздә тотылмаса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп иткәндә;

7) Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты, МФЦ, МФЦның вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы ялгыш

язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартканда яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозганда.

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогы яки тәртибе бозылганда;

9) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының законнарында һәм башка норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган булып та, дәүләт хезмәтү күрсәтү туктатып торылса;

10) дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән беренче тапкыр кабул иткәндә юклыгы яки дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән, дәүләт хезмәте күрсәткәндә яки дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны яки мәгълүматны таләп итү, № 210-ФЗ Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пункты чыгарма булып тора.

5.3. Шикаять язмача кәгазьдә яисә электрон формада бирелә.

Шикаять почта аша, МФЦ аша, «Интернет» мәгълүмати телекоммуникацияләр челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайты (http://mzio.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru), Дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru) аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул итү барышында кабул ителергә мөмкин.

МФЦның, МФЦ хезмәткәренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата шикаять почта аша, «Интернет» челтәрен файдаланып, МФЦның рәсми сайты аша, Татарстан Республикасының дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru), Дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru) аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул итү барышында кабул ителергә мөмкин.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш:

1) карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять белдерелгән дәүләт хезмәте күрсәтүче органның атамасы, органның дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи заты яки дәүләт хезмәткәре, аның җитәкчесе һәм (яки) хезмәткәре;

2) гариза бирүче физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булганда), яшәү урыны турында мәгълүмат, мөрәҗәгать итүче юридик затның атамасы, урнашкан урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры

(номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең, МФЦның шикаять белдерелә торган карарлары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре турында мәгълүмат;

4) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре белән килешмәвенә дәлилләре.

5.5. Шикаятькә анда бәян ителгәннәрне раслый торган документларның күчермәләре беркетелә ала.

5.6. Шикаять ул кергән эш көненнән соңгы көннән дә калмыйча регистрацияләнә.

Шикаять регистрацияләнгәннән соң унбиш көн эчендә карала, ә Министрлыкның гариза бирүчедән документларын кабул итеп алудан баш тартуга яки ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуга яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга карата шикаять белдерелгән очракта - аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

5.7 Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән карарны юкка чыгару рәвешендә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда Министрлык тарафыннан җибәрелгән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә түләтү күздә тотылмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.8. Бу Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгәннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача һәм, гариза бирүченең теләгенә карап, электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип табылса, бу Регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән җавапта дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ясалган кимчелекләрне төзәтү өчен Министрлык кылачак гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук

килеп туган уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәте алу өчен гариза бирүче кылырга тиешле гамәлләр турында мәгълүмат бирелә.

5.10. Шикаять канәгатьләндерелмәсә, бу Регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән җавапта гариза бирүчегә кабул ителгән карар турында дәлилле аңлатма бирелә, кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе бәян ителә.

5.11. Шикаятьне карау барышында яки аның нәтиҗәләре буенча, административ хокук бозу билгеләре яки җинаять ачыкланса, шикаятьләрне карау вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны тиз арада прокуратура органнарына юллый.

5.12. Министрлыкның, шулай ук аның вазыйфаи затларының, яисә дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерүгә бәйле мөнәсәбәтләр № 210-ФЗ Федераль закон нигезендә көйләнә.

Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, милек итеп, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Җир кишәрлекләрен түләүсез файдалануга биргәндә дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап гариза бирүчеләр

Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләре түбәндәгеләргә түләүсез файдалануга бирелә ала:

1) дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына;

2) дәүләти һәм муниципаль учреждениеләргә (бюджет, казна, автоном);

3) казна предприятиеләренә;

4) Россия Федерациясенең үз вәкаләтләрен башкаруны туктаткан президентларының тарихи мирас үзәкләренә;

5) дини оешмаларга дини яисә хәйрия билгеләнешендәге биналарны, корылмаларны урнаштыру өчен, ун елга кадәр срок белән;

6) әгәр ул җирдә түләүсез файдалану хокукында аларга караган биналар, корылмалар урнашкан булса, дини оешмаларга – күрсәтелгән бинага, корылмага хокук срогы беткәнчегә кадәр;

7) "Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эш, хезмәт күрсәтү өлкәсендә контракт системасы турында" 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законга туры китереп, тулысынча Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчасы хисабына күчемсез милек объектлары төзелеше яисә реконструкция буенча гражданлык-хокук шартнамәсе төзелгән затларга, шартнамә башкарылу срогына;

8) тулысынча федераль бюджеттан субсидия буларак алынган акчаларга әлеге җир кишәрлекләрендә капиталь төзелеш объектларын төзү һәм (яки) реконструкцияләү өчен коммерциячел булмаган оешмаларга, төзелеш һәм (яки) капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү срогына;

9) Татарстан Республикасы законнары белән белгеләнгән шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару яки крестьян (фермер) хуҗалыклары эшчәнлеге өчен муниципаль берәмлекләрдә җир кишәрлеге бирелгән гражданнарга, алты елдан да артмаган срокка;

10) Татарстан Республикасы законнары белән белгеләнгән шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмчел хуҗалык шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен муниципаль берәмлекләрдә җир кишәрлеге бирелгән һәм әлеге муниципаль

берәмлекләрдә Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән белгечлекләр буенча эшләүче гражданнарга, алты елдан да артмаган срокка;

11) әлеге җир кишәрлегендә хезмәт торагы булган йорт урнашкан булса, хезмәт торагы итеп йорт бирелгән гражданнарга, әлеге торак йорт белән файдалану срогында;

12) коммерциячел булмаган яшелчәчелек яисә бакчачылык ширкәтләренә - биш елдан да артык булмаган срокка;

13) торак төзелеше максатыннан гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциячел булмаган оешмаларга – федераль законнарда каралган очракларда һәм срокларда;

14) федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты указы, Россия Федерациясе Хөкүмәте норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән аерым категория гражданнарын торак белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы законнарында каралган һәм Татарстан Республикасында төзелгән коммерциячел булмаган оешмаларга – әлеге торакларны төзү максатыннан күрсәтелгән төзелеш вакытында;

15) җир кишәрлеген дәүләт ихтыяҗы өчен алу сәбәпле, Татарстан Республикасы милкендә булган бу җир кишәрлегеннән түләүсез файдалану хокукы бетерелгән затларга – алынган җир кишәрлегеннән түләүсез файдалану хокукына бәйле рәвештә законнар белән билгеләнгән срокларда.

16) «Торак төзелеше үсешенә, туристлык инфраструктурасы объектлары булдыруга һәм территориянең башка үсешенә ярдәм турында» 2008 елның 24 июлендәге № 161-ФЗ Федераль законда каралган затларга шул очракларда һәм тәртиптә;

17) «Почта России» федераль дәүләт унитар предприятиесен реорганизацияләү үзенчәлекләре, «Почта России» акционерлык җәмгыятенең эшчәнлек нигезләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 29 июнендәге № 171-ФЗ Федераль закон нигезендә «Почта России» акционерлык җәмгыятенә;

18) “Төзелеш тармагында бердәнбер заказ бирүче” гаммәви-хокукый компаниясенә - агымдагы елда һәм план периодында эшчәнлек программасына кертелгән инженерлык тикшеренүләрен, архитектура-төзелеш проектлауларын, реконструкцияләр, капиталь ремонт, капиталь төзелеш объектларын сүтү эшләрен тәэмин итү өчен, “Төзелеш тармагында бердәнбер заказ бирүче” гаммәви-хокукый компания турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 22 декабрендәге № 435-ФЗ Федераль законы нигезендә.

19) «Территорияләрнең үсеше фонды» гаммәви-хокукый компаниясенә «Территорияләрнең үсеше фонды» гаммәви-хокукый компаниясе һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 29 июль, 2017 ел, № 218-ФЗ Федераль законда каралган функцияләрне һәм вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен, «Түләргә сәләтсезлек турында (банкротлык)» 2002 ел, 26 октябрь, № 127-ФЗ Федераль законда каралган шартларда күрсәтелгән гаммәви-хокукый компаниягә тапшырылган (тапшырылырга мөмкин булган) җир кишәрлегендә төзелеп бетмәгән объектларны (капиталь төзелеш объектларын төзү) төзеп бетерү Россия Федерациясенең җир һәзм башка законнарында билгеләнгән чикләүләр аркасында мөмкин булмаган очракта, андый чикләүләр Россия Федерациясе Шәһәр төзү кодексына таянып төзелеш өчен рөхсәт бирү вәкаләтләре булган башкарма хакимиятнең федераль органы, Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимияте органы, җирле хакимият органы тарафыннан расланган булса;

20) «Роскадастр» гаммәви-хокукый компаниясенә, «Роскадастр» гаммәви-хокукый компаниясе турында» федераль законына таянып таратылган федераль дәүләт учреждениеләренә даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында бирелгән җир кишәрлекләренә мөнәсәбәтле.

Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, милек итеп, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Киңәш ителгән форма

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы

Җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында бирү турында боерык

| | |
|---|---|
| ___________________ | № __________ |
| *карарның датасы* | карарның *номеры* |

Җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында бирү турында №___________ ______ (гариза бирүче: ______________________________) гаризаны карау нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясенең Җир Кодексының ________________ таянып:

1. Гариза бирүчегә ___________________________________________ әлеге Боерыкның кушымтасында күрсәтелгән җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында бирергә.

2. “Республика мөлкәт казнасы” дәүләт бюджет учреждениесенә әлеге Карар кабул ителгәннән соң 5 эш көне эчендә әлеге Карарның 1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукын регистрацияләү өчен күчемсез милеккә хокукны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләти регистрацияләүче органга мөрәҗәгать итәргә тәкъдим итергә.

3. Гариза бирүчегә __________________________ әлеге Карарның 1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлегендә билгеләнгән саклау зоналары таләпләрен үтәүне тәэмин итергә.

4. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны _______________________________________ йөкләргә.

________________________

(вазыйфа, Ф.И.ӘИ.) (соңгысы – булса)

№ _____
«___»_______________
Боерыкка кушымта

Даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында бирелгән җир кишәрлекләре исемлеге

_______________________________________________
*(гариза бирүче атамасы)*

| № п/п | Җир кишәрлеге урнашу урыны (адрес) | Рөхсәт ителгән куллану төре | Җир категориясе | Җир кишәрлегенең кадастр номеры | Җир кишәрлеге мәйданы, кв.м | Учреждение атамасы | Җир кишәрлегендә урнашкан күчемсез милек объекты атамасы | Күчемсез милек объектларына хокукны раслаучы документ атамасы | Җир кишәрлегенең кадастр бәясе, сум. |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| | | | | | | | | | |
| | Барлыгы: | | | | | | | | |

Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, милек итеп, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Киңәш ителгән форма

___________________________________
(наименование юридик затның атамасы)

___________________________________
(физик затның фамилиясе, инициаллары)

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән
баш тарту турында карар

_____________________________ № ________белән теркәлгән гариза нигезендә, түбәндәге нигезләр таянып дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителде:______________________________________.

Баш тарту сәбәпләренә аңлатма:_______________________________________
_______________________________________________________________________

Өстәмә мәгълүмат: _________________________________________.
(дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту сәбәпләрен бетерү өчен кирәкле белешмә бирелә, булса, башка өстәмә мәгълүматлар да күрсәтелә)

Сез күрсәтелгән кимчелекләр төзәтелгәннән соң хезмәт күрсәтүне сорап кабат Министрлыкка мөрәҗәгать итә аласыз.

Әлеге баш тарту судка кадәр Министрлыкка шикаять итү юлы белән яки суд тәртибендә шикаять ителә ала.

____________________________________
(вазыйфа, Ф.И.ӘИ.) (соңгысы – булса)

Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, милек итеп, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

Киңәш ителгән форма

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрына

_______________________________________________

(кемнән)_________________________________________
__

(физик затлар өчен - фамилия, исем һәм (булганда) әтисе исеме, яшәү урыны, шәхесне раслаучы документ реквизитлары)

____________________________________

(юридик затлар өчен - атамасы, урнашу урыны, оештыру-хокукый формасы, ОГРН, ИНН, чит ил юридик заты гариза бирүче булган очраклар искәрмә булып тора)

____________________________________

(почта адресы, электрон почта адресы, элемтә өчен телефон номеры)

## Җир кишәрлеген сатулашулар үткәрмичә милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү турында гариза

________________________________________________________________________________

(кирәклесенең астына сызарга)

_______________________________________________________ нигезендә

(РФ ҖКның $39^{3}$ст. 2 п., $39^{6}$ ст. 2 п., $39^{9}$ ст. 2 п. яки $39^{10}$ ст. 2 п., “Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең әйләнеше турында” 2002 елның 24 июлендәге № 101-ФЗның $10^{1}$ ст. нигез буларак күрсәтелә)

_______________________________________________________

(җир кишәрлеген куллану максаты күрсәтелә)

________кадастр номерлы, мәйданы ___________ кв.м. булган, куллану өчен рөхсәт ителгән төре ___________________, _______________ категориясеннән, ________________________ адресы буенча урнашкан җир кишәрлеген сатулашулар уздырмыйча милек итеп, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, ______ вакытка түләүсез файдалануга бирүегезне үтенәм.

(кирәклесенең астына сызарга)

Өстәмә белешмә (түбәндәге шартлар булганда тутырыла): ____________________________________________________________________________;

җир кишәрлеге дәүләт ихтыяҗы өчен тартып алынган җир кишәрлеге урынына бирелгән очракта, җир кишәрлеген дәүләт ихтыяҗы өчен тартып алу турында карарның реквизитлары;

_______________________________________________________________________________

соралган җир кишәрлеге ясалган яки аның чикләре әлеге карар нигезендә төгәлләштерелгән булса, җир кишәрлеге бирүне беренчел килештерү турында карар реквизитлары.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен:

- юлларга ___________________________________________________;

(күрсәтелә: электрон документ формасында, электрон документның кәгазьгә төшерелгән экземпляры рәвешендә МФЦга; Республика порталындагы шәхси кабинетка);

- Министрлыкта бирергә ____________________

_________________________________________________________________.

(күрсәтелә: кәгазь документ рәвешендә, электрон документ формасында яки электрон документның кәгазьгә төшерелгән экземпляры рәвешендә)

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында телефон аша уздырылган сораштыруда телефон аша катнашырга ризалыгымны бирәм: ______________________.

______________ ________________ ( ________________)

(дата) (имза) (фамилия, исем һәм әтисе исеме (булса)

М.П.

(булса юридик затлар өчен)

Җир кишәрлеген бирү турындагы
гаризага 1 нче кушымта

Җир кишәрлеген бирү турындагы
гаризага беркетелгән документлар исемлеге

| Документ атамасы | Битләр саны |
|---|---|
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |

Гариза бирүче (ышанычнамә буенча вәкил)

______________________________ ______________________________
(фамилия, инициаллар) (имза)

Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белгече

______________________________ ______________________________
(фамилия, инициаллар) (имза)

Барлык документлар да 1 данәдә

Җир кишәрлеге бирү турында гаризага
2 нче кушымта

Киңәш ителгән форма

Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрына

_______________________________________
(Фамилия, инициаллар)

_______________________________________
(Персональ мәгълүмат субъектының фамилиясе, инициаллары)

Персональ мәгълүмат субъектының
персональ мәгълүматны эшкәртүгә ризалыгы

Мин,

_________________________________________________________________ ,
(фамилия, исем, әтисе исеме (булса)
паспорт серия _____ № _________ бирелгән «____» _____________ел
_________________________________________________________________ ,
(кем тарафыннан бирелгән)
__________________________________________адресы буенча
регистрацияләнгән/яши:
_________________________________________________________________ ,
почта адресы: ________________________________________________ ,
яки электрон почта адресы: ____________________________________ ,
телефон: ______________________________ ,
Персональ мәгълүмат субъекты вәкиле йөзендә (персональ мәгълүмат субъекты вәкиленнән ризалык алынган очрак тутырыла)
_________________________________________________________________
(фамилия, исем, әтисе исеме (булса)
паспорт серия _______ № ___________ бирелгән «___»________________
_________________________________________________________________
_________ (кем биргән)
адресы буенча теркәлгән/яши

персональ мәгълүмат субъекта исеменнән _____________________________
_________________________________________________нигезендә гамәл кыла
(вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы ышанычнамәнең яки башка документның реквизитлары)

Персональ субъектның хокукларын һәм ирегең саклауны тәэмин итүче Россия Федерациясе законнарындагы таләпләрнең саклануы максатларында персональ мәгълүматны эшкәртергә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына (ОГРН _____________, ИНН __________),

420043, ТР, Казан ш., Вишневский ур., 26 й. адресы буенча теркәлгән, «Интернет» мәгълүмати телекоммуникацияләр челтәрендәге рәсми сайты (http://mzio.tatarstan.ru) (алга таба – оператор),

___________________________________________________________

(юридик затның тулы атамасын, әгәр дә персональ мәгълүматны эшкәртү билгеле беро затка йөкләнгән блуса, аның фамилиясен, исемен, әтисе исемен (булса) һәм адресын күрсәтергә)

үземнең персональ мәгълүматымны автоматлаштырылган, шулай ук, авматлаштыру чараларыннан башка, эшкәртергә ризалык бирәм, аерыс алганда:

эшкәртергә рөхсәт ителгән персональ мәгълүмат:

- фамилия, исем, әтисе исеме;
- туган ел, ай, дата һәм урын;
- гражданлык турында таныклык (кирәк булса);
- шәхесне раслаучы документ реквизитлары;
- салым түләүченең идентификация номеры, өчетка кую датасы, салым органында учетка кую таныклыгы реквизитлары;
- мәҗбүри пенсия иминиятләштерү таныклыгы номеры, мәҗбүри пенсия иминиятләштерү системасында регистрацияләү датасы (кирәк булса);
- фактик яшәгән урыны адресы һәм яшәгән һәм (яки) торган урыны регистрациясе;
- почта һәм электрон адресы;
- телефоннары номерлары;
- гаилә һәм һәм гаилә составы турында мәгълүмат (кирәк булса);
- мал-мөлкәте, кереме, бурычлары турында мәгълүмат (кирәк булса),

*“Персональ мәгълүматлар турында” 27.07.2006 ел, №152-ФЗ Федераль законның 3 статьясының 3 пунктынада каралган гамәлләрне кылу өчен, аерым алганда:*

*Эшкәртергә рөхсәт ителгән персональ мәгълүматка бәйле гамәлләр исемлеге: персональ мәгълүматны җыюны, яздыруны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, аныклауны (яңарту, үзгәртү), файдалану, тапшыру (тарату, бирү), блоклауны, бетерүне, юкка чыгаруны да кертеп, автоматлаштыру чаралары белән яки алардан башка эшкәртергә рөхсәт бирәм.*

Персональ мәгълүматны эшкшртүгә әлеге ризалык алар оперторга бирелгән вакыттан башлап «____» ___________20___ елга кадәр гамәлдә була һәм теләсә кайсы вакытта операторга язмача гади гариза биреп соратып алына ала.

_________________________ /_________________/ «__» ________ 20__ ел

(фамилия, исем, әтисе исеме (булса) (имза) (дата)

Җир кишәрлеге бирү турында гаризага
3 нче кушымта

Рекомендуемая форма

Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрына

____________________________________
(Фамилия, инициаллар)

____________________________________
(Фамилия, персональ мәгълүмат субъектының инициаллары)

Персональ мәгълүмат субъекты тарафыннан таратырга рөхсәт ителгән персональ мәгълүматны эшкәртүгә ризалык

Мин,

____________________________________________________________ ,
(фамилия, исем, әтисе исеме (булса)

паспорт серия _____ № _________ бирелгән «____» _____________ел

____________________________________________________________________ ,
(кем тарафыннан бирелгән)

_______________________________________адресы буенча регистрацияләнгән/яши:

____________________________________________________________________ ,

почта адресы: ______________________________________________________ ,

яки электрон почта адресы: __________________________________________ ,

телефон: ___________________________

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына (ОГРН _____________, ИНН __________), 420043, ТР, Казан ш., Вишневский ур., 26 й. адресы буенча регистрацияләнгән, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендәге рәсми сайты (http://mzio.tatarstan.ru) (алга таба – оператор) үз персональ мәгълүматымны эшкәртергә ризалык бирәм.

Персональ мәгълүмат субъекты вәкиле йөзендә (персональ мәгълүмат субъекты вәкиленнән ризалык алган очракта тутырыла) ____________________________________________________________
(фамилия, исем, әтисе исеме (булса)

паспорт серия _______ № ___________ бирелгән «___»_________________

_____________________________________________________________________
(кем биргән)

________________________________________ адресы буенча регистрацияләнгән / яшәүче,

______________________________________________________________________
(вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы ышанычнамә яки башка документ реквизитлары)
___________________________________________ нигезендә персональ мәгълүмат субъекты исеменнән гамәл кылучы

Персональ мәгълүматны эшкәртү максаты:

- Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәүне тәэмин итү;

- персональ мәгълүматны җыю, яздыру, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), файдалану, тапшыру (тарату, бирү), блоклау, бетерү, юкка чыгару;

______________________________________________________________________

Эшкәртергә рөхсәт ителгән персональ мәгълүмат:

- фамилия, исем, әтисе исеме;
- туган ел, ай, дата һәм урын;
- гражданлык турында таныклык (кирәк булса);
- шәхесне раслаучы документ реквизитлары;
- салым түләүченең идентификация номеры, өчетка кую датасы, салым органында учетка кую таныклыгы реквизитлары;
- мәҗбүри пенсия иминиятләштерү таныклыгы номеры, мәҗбүри пенсия иминиятләштерү системасында регистрацияләү датасы (кирәк булса);
- фактик яшәгән урыны адресы һәм яшәгән һәм (яки) торган урыны регистрациясе;
- почта һәм электрон адресы;
- телефоннары номерлары;
- гаилә һәм һәм гаилә составы турында мәгълүмат (кирәк булса);
- мал-мөлкәте, кереме, бурычлары турында мәгълүмат (кирәк булса),

Оператор йөкләмәсе буенча персональ мәгълүматны эшкәртүче затның атамасы яки фамилиясе, исеме, әтисенең исеме һәм адресы, әгәр дә эшкәртү андый кешегә йөкләнгән булса _______________

______________________________________________________________________
(оператор йөкләмәсе буенча персональ мәгълүматны эшкәртүче юридик затның тулы атамасы атамасы яки фамилиясе, исеме, әтисенең исеме һәм адресы)

Эшкәртүгә ризалык бирелгән персональ мәгълүматка бәйле гамәлләр исемлеге, персональ мәгълүматны эшкәртүнең оператор кулланган ысуллары:

Алда күрсәтелгән персональ мәгълүмат катнаш (автоматлаштырылган, автоматлаштырылмаган) ысул белән эшкәртелә.

Персональ мәгълүматны җыю, яздыру, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), файдалану, тапшыру (тарату, бирү), блоклау, бетерү, юкка чыгару (чынлап та кулланылган мәгълүматка кагыла)

Алда күрсәтелгән персональ мәгълүматны эшкәртү ________________________________________________
(эшкәртү ысулын күрсәтергә (кушма, автомалаштырылган, автоматлаштырылмаган)
ысулы белән алып барыла.

Операторга минем мәгълүматны __________________________________
____________________________________________________________________
____________________________________________________________________
(юридик затның тулы атамасын күрсәтергә; тапшырырга ризалык бирелгән физик затның фамилиясе, исеме, әтисе исеме һәм адресы)
______________________________________________________________ ысулы
(персональ мәгълүматка үтеп керү)
белән тапшырырга рөхсәт ителәә

Персональ мәгълүмат субъектының ризалыгы гамәлдә булган вакыт, шулай ук аны соратып алу ысулы, федераль законга башкача күрсәтелмәсә:

Персональ мәгълүматны эшкәртүгә әлеге ризалык алар оперторга бирелгән вакыттан башлап «____» ___________20___ елга кадәр гамәлдә була һәм теләсә кайсы вакытта операторга язмача гади гариза биреп соратып алына ала.

Субъектның персональ мәгълүматы Россия Федерациясе законнарында күрсәтелгән вакытта саклanырга тиешле. Персональ мәгълүмат юкка чыгарыла: персональ мәгълүматны эшкәртү максатларына ирешелгәч; оператор юкка чыгарылгач яки үзгәртелгәч; персональ мәгълүмат субъектының аның персональ мәгълүматын эшкәртүне таләп итеп язмача мөрәҗәгатеннән соң оператор персональ мәгълүматны эшкәртүне 3 (өч) эш көне эчендә туктата, шул хакта 10 (ун) эш көне эчендә персональ мәгълүмат субъектына язмача белдерү юллана.

_________________________ /_________________/ «__» ________ 20__ ел
(фамилия, исем, әтисе исеме (булса)   (имза)   (дата)

Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, милек итеп, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

Җир кишәрлеген сатулашулар үткәрмичә милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирүдән баш тарту өчен нигезләр

Әлеге нигезләрнең берсе генә булса да, Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлеген сатулашулар үткәрмичә милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирүдән баш тарту кабул ителә:

1) с җир кишәрлеге бирү турында гариза белән җир законнары буенча җир кишәрлеген сатулашулар үткәрмичә алу хокукы булмаган зат мөрәҗәгать итә;

2) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану, түләүсез файдалану, гомерлеккә мирас ителгән биләмәләр яки аренда хокукында бирелгән; җир кишәрлеге бирү турында гариза белән әлеге хокуклары булган кеше мөрәҗәгать итүе яисә җир кишәрлеге бирү турында гариханың РФ ҖКның $39^{10}$ статьясының 2 пункты 10 подпунктына туры китереп бирелгән булуы чыгарма булып тора;

3) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге яшелчәчелек яки бакчачылык коммерциячел булмаган ширкәтенә бирелгән җирне бүлеп ясалган; әлеге коммерциячел булмаган ширкәтнең әгъзасы (әлеге җир кишәрлеге бакча яки яшелчә җире булса) яисә, гражданнар үз ихтыяҗлары өчен яшелчәчелек яки бакчачалык эше алып барган территория чигендәге җир кишәрлекләренең милек иясе (җир кишәрлеге гомуми файдаланыла торган милеккә кергән очракта) мөрәҗәгать иткән очраклар чыгарма булып тора;

4) җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлегендә гражданнарга яки юридик затларга караган биналар, корылмалар, төзелеп бетмәгән объектлар урнашкан; корылма (шул исәптән, төзелеп бетмәгән корылма) җир кишәрлегендә сервитут, гаммәви сервитут шартларында, яки РФ ҖКның $39^{36}$ статьясы нигезендә урнашкан объектлар урнашкан очраклар яисә җир кишәрлеген үзенә бирү турындагы гариза белән әлеге бинаның, корылманың, төзелеп бетмәгән объектның хосусый милек иясе мөрәҗәгать иткән очраклар, шулай ук, җир кишәрлеге бирү турында гариза

бирелгән һәм әлеге җир кишәрлегендә үзбелдекле төзелгән бинаны, корылманы, төзелеп бетмәгән объектны сүтү турында, яки үзбелдекле төзелешне сүтү яисә билгеләнгән срокларда билгеләнгән таләпләргә туры китерү турында кабул ителгән карар һәм Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексының 55[32] статьясының 11 өлеше үтәлмәгән очраклар чыгарма булып тора;

5) җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегендә дәүләт яки муниципаль милек булган бина, корылма, төзелеп бетмәгән объект урнашкан булса, әлеге җир кишәрлегендә урнашкан корылмаларның (шул исәптән, төзелеп бетмәгән корылмаларның) җир кишәрлегендә урнашуы сервитут шартларында, гаммәви сервитут шартларында рөхсәт ителсә яки РФ ЖК 39[36] статьясына туры китереп урнаштырылган объектлар булса, яки җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгать белән әлеге бина, корылма, алардагы бүлмәләрнең, әлеге төзелеп бетмәгән объектның хокук иясенең чыгуы чыгарма булып тора;

6) җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге әйләнештән алынган яисә әйләнеше чикләнгән булса һәм аны бирү җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән хокукта каралмаган булса;

7) җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен резервка куелган булса, ә гариза бирүче җир кишәрлеген милеккә, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану өчен яки җир кишәрлеген арендага, җир кишәрлегенең резервы турындагы карарның гамәлдәге вакытыннан озынрак срокка түләүсез файдалануга бирү турында мөрәҗәгать итсә, җир кишәрлеген резервка кую максатларында бирү очрагы чыгарма булып тора;

8) җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге башка зат белән территорияне үсеше турында шартнамә төзелгән яки күрсәтелгән карарны тормышка ашыру өчен территориянең комплекслы үсеше турында шартнамә төзү таләп ителмәгән очракта комплекслы үсеш турында карар кабул ителсә территория чикләрендә урнашкан булса, җир кишәрлеге бирү турында шушы җир кишәрлегендә урнашкан бина, корылма, алардагы бүлмә, төзелеп бетмәгән объект милекчесенең яки әлеге җир кишәрлегенә хокукы булган затның мөрәҗәгате чыгарма булып тора;

9) җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге башка зат белән территорияне үсеше турында шартнамә төзелгән яки күрсәтелгән карарны тормышка ашыру өчен территориянең комплекслы үсеше турында шартнамә төзү таләп ителмәгән очракта комплекслы үсеш турында

карар кабул ителсә территория чикләрендә урнашкан булса, яки җир кишәрлеге башка зат белән территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә төзелгән җир кишәрлегеннән ясалган булса, әлеге җир кишәрлегенең федераль дәрәҗәдәге объектлар, региональ дәрәҗәдәге объектлар яки җирле дәрәҗәдәге объектлар урнаштыру өчен тәгаенләнгән булып, шул җир кишәрлеген бирү турында күрсәтелгән объектларны төзергә вәкаләтле затның мөрәҗәгате чыгарма булып тора;

10) җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә яки төзелгән территорияне үстерү турында шартнамә төзелгән җир кишәрлегеннән ясалган, яки күрсәтелгән карарны тормышка ашыру өчен территориянең комплекслы үсеше турында шартнамә төзү таләп ителмәгән очракта комплекслы үсеш турында карар кабул ителсә, һәм территориянең планировкасы буенча расланган документация нигезендә федераль дәрәҗәдәге объектлар, региональ дәрәҗәдәге объектлар яки җирле дәрәҗәдәге объектлар урнаштыру өчен тәгаенләнгән булса, җир кишәрлеген арендага бирү турында территорияне комплекслы үзләштерү буенча шартнамә төзелгән яки әлеге объектларны төзү бурычы куелып, территорияне үстерү турында шартнамә төзелгән затның мөрәҗәгате чыгарма булып тора;

11) җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге аукцион предметы булып тора, аны үткәрү турныда хәбәр РФ ҖК $39^{11}$ статьясының 19 пункты нигезендә урнаштырылган;

12) җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә мөнәсәбәтле рәвештә РФ ҖК $39^{11}$ статьясының 4 пункты 6 подпунктында каралган аны сату буенча аукцион үткәрелү, яки әлеге җир кишәрлеге РФ ҖК $39^{11}$ статьясының 4 пункты 4 подпункты нигезендә ясалган булып, вәкаләтле орган тарафыннан РФ ҖК $39^{11}$ статьясының 8 пунктында каралган нигезләр буенча әлеге аукционны үткәрүдән баш тарту турында карар кабул ителмәгән очракта, аренда шартнамәсенә хокукка аукцион үткәрелү турында гариза кергән булса;

13) җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә мөнәсәбәтле рәвештә җир кишәрлеген хосусый торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, гражданнарга үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яки крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлегенә бирү турында РФ ҖК $39^{18}$ статьясының 1 пункты 1 подпункты нигезендә хәбәр бастырылган һәм урнаштырылган булса;

14) җир кишәрлеген рөхсәт ителгәнчә куллану җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән куллану максатларына туры килмәсә, территорияне планировкалауның расланган проекты нигезендә линияле объект урнаштыру очраклары искәрмә булып тора;

15) соралган җир кишәрлеге тулысынча территорияне куллануның аерым шартлары булган зона чикләрендә урнашкан, җир кишәрлеген куллануның билгеләнгән чикләүләре җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән куллану максатларына туры килми;

16) соралган җир кишәрлеге, оборона һәм иминлек ихтыяҗында куллану өчен бирелгән һәм вакытлыча күрсәтелгән максатларында файдаланылмаган җир кишәрлекләренең Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә расланган исемлегенә кертелмәгән булса, җир кишәрлеген бирү турында РФ ҖК $39^{10}$ статьясының 2 пункты 10 подпункты нигезендә мөрәҗәгать ителгән очракта;

17) җир кишәрлеген бакчачылык, яшелчәчелек ширкәтенә бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенең мәйданы РФ ҖК $39^{10}$ статьясының 6 пунктында билгеләнгән чикләрдәге зурлыктан артса;

18) җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территориаль планлаштыруның расланган документлары һәм (яисә) территориянең планировкасы буенча расланган документация нигезендә, федераль дәрәҗәдәге объектлар, региональ дәрәҗәдәге объектлар яки җирле дәрәҗәдәге объектлар урнаштыру өчен тәгаенләнгән булса һәм җир кишәрлеген бирү турында гариза белән әлеге объектларны төзү буенча вәкаләтле зат мөрәҗәгать итмәгән булса;

19) җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге Россия Федерациясе дәүләт программасы, Татарстан Республикасы дәүләт программасы нигезендә биналар, корылмалар урнаштыру өчен тәгаенләнгән булса һәм җир кишәрлеген бирү турында гариза белән әлеге бинаны, корылманы төзү буенча вәкаләтле зат мөрәҗәгать итмәгән булса;

20) җир кишәрлеген хокукларның билгеләнгән төрендә бирү рөхсәт ителми;

21) җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата файлануның рөхсәт ителгән төрләре билгеләнмәгән;

22) җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге җирләрнең аерым категорияләренә кертелмәгән;

23) җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә мөнәсәбәттә аны бирүне алдан килештерелү турында карар кабул ителгән һәм

карарның срогы чыкмаган, әлеге җир кишәрлеген бирү турында гариза белән әлеге карарда күрсәтелмәгән башка зат мөрәҗәгать итсә;

24) җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге дәүләт яки муниципаль ихтыяждан чыгып тартып алынган һәм әлеге җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән максатлар әлеге җир тартып алынган максатларга туры килмәсә, тузган булып танылган һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш булган күп фатирлы йортның әлеге дәүләт яки муниципаль ихтыяждан чыгып тартып алынган җир кишәрлегендә урнашкан булуы чыгарма булып тора;

25) җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенең чикләре “Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында” 2015 елның 13 июлендәге № 218-ФЗ Федераль Закон нигезендә төгәлләштерелергә тиеш;

26) җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән җир кишәрлегенең мәйданы җир кишәрлегенең урнашу схемасында, территорияне ызанлау проектында яки җир кишәрлеге барлыкка китерелгән урман кишәрлекләренең проект документациясендә җир кишәрлеге күрсәтелгән мәйданнан ун проценттан артыграк зуррак булса;

27) «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекнең үсеше турында» 2007 елның 24 июлендәге № 209-ФЗ Федераль законның 18 статьясындагы 4 бүлегендә каралган дәүләт милке яки муниципаль милек исемлегенә кертелгән җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгать белән кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты булмаган зат, яисә Федераль законның 14 статьясының 3 бүлеге нигезендә ярдәм күрсәтелми торган зат мөрәҗәгать итсә.

28) җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенең мәйданы дәүләт яки муниципаль милектәге авыл хуҗалыгы җирләреннән гражданинга яки крестьян (фермер) хуҗалыгына крестьян (фермер) эшчәнлеге (алга таба – гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге), яисә гражданинга яки крестьян (фермер) хуҗалыгына крестьян (фермер) эшчәнлеге өчен гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеген дә исәпләп, бирелгән җир кишәрлекләренең мәйданы крестьян (фермер) эшчәнлеген тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән җир кишәрлекләре мәйданына туры килми;

29) гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге алдарак кергән җир кишәрлеген бирү турында гариза буенча дәүләт яки муниципаль милектәге авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән гражданинга яки крестьян (фермер) хуҗалыгына крестьян (фермер) эшчәнлеге өчен бирелгән.

Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, милек итеп, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 6 нчы кушымта

ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында җир кишәрлеге бирү турында гариза үтү бите

Гариза бирүче ____________________________________________
Регистрация (керү) номеры _______________________

| № п/п | Министрлыкның структур бүлекчәсе | Алу датасы | Имза | Тапшыру датасы | Имза |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Җир ресурслары идарәсенең дәүләт җирләреннән нәтиҗәле файдалану бүлеге белгече | | | | |
| 2 | Контроль бүлеге | | | | |
| 3 | Җир ресурслары идарәсенең дәүләт җирләреннән нәтиҗәле файдалану бүлеге белгече | | | | |
| | Килештерүләр: | | | | |
| 4 | Җир ресурслары идарәсенең дәүләт җирләреннән нәтиҗәле файдалану бүлеге мөдире | | | | |
| 5 | Җир ресурслары идарәсе башлыгы | | | | |
| 6 | Хокук идарәсе башлыгы | | | | |
| 7 | Хокук идарәсе белгече | | | | |
| 8 | Хокук идарәсе башлыгы | | | | |
| 9 | Министрның беренче урынбасарының кабул итү бүлмәсе (документларны имзалау) | | | | |
| 10 | Министрның кабул итү | | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | бүлмәсе (документларны имзалау) | | | | |
| 11 | Контроль бүлеге (Документларны формалаштыру һәм регистрацияләү) | | | | |

Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, милек итеп, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 7 нче кушымта

Киңәш ителгән форма

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрына ______________________
__________________________________________________

(Кемнән) _________________________________
(физик затлар өчен – фамилия, исеме, әтисенең исеме (соңгысы - булса), яшәгән урыны, шәхесен раслаучы документ реквизитлары
__________________________________________________
(юридик затлар өчен - атамасы, урнашкан урыны, оештыру-хокукый формасы, ОГРН, ИНН, гариза бирүче чит ил юридик заты булган очраклар искәрмә булып тора)
__________________________________________________
(почта адресы, электрон почта адресы, элемтә өчен телефон номеры)

Техник хатаны төзәтү турында
гариза

Татарстан Республикасы милке булган җир кишәрлеген физик яки юридик затларга сатулашулар уздырмыйча милек итеп, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм: ___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________

Дөрсе мәгълүмат: __________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________

«____»_________ 20______г. №________ җир кишәрлеге бирү турындагы карарда, җир кишәрлеген сату-алу, аренда шартнамәсендә, җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану, түләүсез файдалану шартнамәсендә техник хатаның төзәтелүен һәм тиешле үзгәрешләр кертелүен үтенәм.

Түбәндәге документларны беркетәм:

1.
2.
3.

Дәүләт хезмәте күрсәтелүе турында (күрсәтүдән баш тарту турында) мәгълүматны
___________________________________________________________________________

____(язмача, электрон почта белән, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципапль хезмәтләр порталында Шәхси кабинетка)

_______________________________________________________алырга риза

________________ ___________________ ( __________________)

(дата) (имза) (фамилия, исеме, әтисенең исеме (булса)

М.П.(мөһер булганда)

Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, милек итеп, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 8 нче кушымта

Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлеген гражданинга яки юридик затка сатып милеккә бирү очраклары

Сатулашулар уздырмыйча сату мөмкинлеге булган очраклар:

1) территорияне комплексны үзләштерү максатларында «Торак төзелеше үсешенә, туристлык инфраструктурасы объектлары булдыруга һәм территориянең башка үсешенә ярдәм турында» 24 июль, 2008 ел, № 161-ФЗ Федераль закон нигезендә төзелгән аренда шартнамәсе яки түләүсез файдалану шартнамәсе буенча бирелгән җир кишәрлегеннән ясалган җир кишәрлекләре;

2) коммерциячел булмаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтенә бирелгән җир кишәрлекләреннән ясалган җир кишәрлекләре, гомуми кулланылыштагы җир кишәрлекләрен әлеге ширкәт әгъзаларына бирү чыгарма булып тора;

3) биналар, корылмалар урнашкан җир кишәрлекләре әлеге биналар, корылмалар яки алардагы бүлмәләрнең милекчеләренә РФ ҖК $39^{20}$ статьясы белән каралган очракларда;

4) юридик затларда даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануда булган җир кишәрлекләре – әлеге юридик затларга, РФ ҖК $39^{9}$ ЗК статьясының 2 пунктында күрсәтелгән затлар искәрмә булып тора;

5) “Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр әйләнеше турында” 2002 елның 24 июлендәге № 101-ФЗ Федераль законда билгеләнгән очракларда – җир кишәрлекләрен крестьян (фермер) хуҗалыгына яки авыл хуҗалыгы оешмасына;

6) авыл хуҗалыгы эшчәнлеге алып бару өчен билгеләнгән һәм гражданинга яки юридик затка арендага бирелгән җир кишәрлеген – әлеге гражданин яки юридик зат белән шартнамә төзелгәнгә өч ел үткәннән соң яисә әлеге гражданин яки юридик зат тарафыннан әлеге җир кишәрлегенең аренда шартнамәсендә күрсәтелгән вакыт беткәнче үк сатулашулар уздырмыйча әлеге җир кишәрлеген сату-алу шартнамәсе төзү турында гариза бирелгән булса, вәкаләтле органда дәүләт җир күзәтчелеге кысаларында әлеге җир белән файдаланганда Россия Федерациясе законнарын бозу очраклары ачыклануы һәм аның төзәтелмәве турында мәгълүмат булмаса, әлеге гражданинга яки

юридик затка аренда шартнамәсе буенча җир кишәрлегенең хокукларын һәм бурычларын тапшыру;

7) ) яңа редакциядә бәян итәргә: җир кишәрлекләрен гражданнарга шәхси торак төзелеше, торак пункты чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, шәхси ихтыяҗ өчен бакчачылык, РФ ҖК $39^{18}$ статьясы нигезендә гражданнарга яки крестьян (фермер) хуҗалыкларына крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлеге алып бару өчен.

Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, милек итеп, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 9 нчы кушымта

## Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлеген гражданинга яки юридик затка арендага бирү очраклары

Җир кишәрлегенә аренда шартнамәсе түбәндәге очракларда сатулашулар уздырылмыйча төзелә:

1) җир кишәрлеген Россия Федерациясе Президенты указы яки боерыгы нигезендә юридик затларга биргәндә;

2) җир кишәрлеген Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә социаль-мәдәни билгеләнештәге объектлар урнаштыру, масштаблы инвестиция проектларын гамәлгә кую өчен, әлеге объектларның, инвестиция проектларының Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән критерийларга туры килүе шарты белән, юридик затларга биргәндә;

3) җир кишәрлеген Татарстан Республикасы Рәисе боерыгы нигезендә социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектлар урнаштыру, масштаблы инвестиция проектларын гамәлгә кую өчен, әлеге объектларның, инвестиция проектларының Татарстан Республикасы законнары белән билгеләгән критерийларга туры килүе шарты белән, юридик затларга биргәндә;

4) җир кишәрлеген «Бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында» 2002 ел, 26 октябрь, № 127-ФЗ Федераль законга таянып банкрот дип танылган йорт салучыга, «Күпфатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 ел, 30 декабрь, № 214-ФЗ Федераль законы нигезендә акчалары күпфатирлы йортлар төзелешенә җәлеп ителгән һәм хокуклары бозылган гражданнар алдында йорт салучы йөкләмәсен башкаруны тәэмин итү өчен, «Бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында» 2002 ел, 26 октябрь, № 127-ФЗ Федераль законның $201^3$ статьясың 1 пункты нигезендә кредиторларның таләпләрен һәм бурычлының мәнфәгатьләрен тәэмин итү буенча арбитраж суд тарафыннан чаралар кабул ителгән очракта;

5) җир кишәрлеген «Бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында» 2002 ел, 26 октябрь, № 127-ФЗ Федераль законга таянып банкрот дип танылган йорт салучыга - «“Территорияләрнең үсеше фонды” гаммәви-хокукый компания турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 29 июль, 2017 ел, № 218-ФЗ Федераль законга таянып, гражданнар алдында күпфатирлы йорт төзелешен тәмамлау яки бурычларын кайтару йөкләмәсен кабул итеп алган “Территорияләрнең үсеше фонды” гаммәви-хокукый компаниясенә бирү өчен;

6) җир кишәрлеген Россия Федерациясенең халыкара бурычларын үтәү өчен, шулай ук, юридик затларга электр, җылылык, газ һәм су тәэмин итү, су агызу, элемтә өчен билгеләнгән объектларны, нефть үткәргечләрне, федераль, региональ һәм җирле дәрәҗәдәге объектлары урнаштыру өчен биргәндә;

7) дәүләт яки муниципаль милектә булган җир кишәрлегеннән ясалган җир кишәрлеген, шул исәптән территорияне комплекслы үзләштерү өчен әлеге җир кишәрлегенә аренда шартнамәсе төзелгән затка бирелгәндә, әлеге кушымтаның 10 подпункты белән, РФ ҖКның 46 статьясының 5 пункты белән башкасы каралмаган очракта;

8) җир кишәрлеге коммерциячел булмаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтенә бирелгән җир кишәрлегеннән ясалган очракта, гомуми файдалану милкенә кертелгән җир кишәрлекләренең әлеге ширкәт әгъзаларына бирелүе чыгарма булып тора;

9) җир кишәрлеге гражданнарга шәхси ихтыяҗларда бакчачылык яки яшелчәчелек эше алып бару территориясе чикләрендә урнашкан гомуми билгеләнештәге әйләнеше чикләнгән җир кишәрлеге, арендатор ягында күпчелек затлар белән әлеге территориядәге бакчачылык яки яшелчәчелек җир кишәрлекләренең милекчесе булган гражданнарга (күрсәтелгән җир кишәрлеген әлеге гражданнарга бирү зарурилыгы коммерциячел булмаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтенең әлеге территория чикләрендәге гомуми кулланылыштагын милек белән идарә итә торган гомуми җыелышында каралган булса);

10) җир кишәрлеген өлешләп төзелештә катнашучыларга, «Күпфатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 ел, 30 декабрь, № 214-ФЗ Федераль законында каралган очракларда;

11) биналар, корылмалар урнашкан җир кишәрлеген биналар, корылмалар һәм алардагы бүлмәләр милекчеләренә һәм (яки) әлеге күчемсез милек

объектлары хуҗалык алып бару хокукында яки РФ ҖК 39[20] статьясында каралган очракларда оператив идарә хокукында бирелгән затларга;

12) төзелеп бетмәгән объектлар урнашкан җир кишәрлекләре, РФ ҖК 39[6] статьясының 5 пунктында каралган очракларда, әлеге төзелеп бетмәгән объектларның хуҗаларына төзелешне тәмамлау өчен бер тапкыр бирелгәндә;

13) юридик затлар даими (вакыты чикләнмәгән) файдалана торган җир кишәрлеге әлеге җирдән файдалунчыларга бирелгәндә, РФ ҖК 39[9] статьясының 2 пунктында күрсәтелгән юридик затлар яисә җир кишәрлеге РФ ҖК гамәлгә кергәнче гомерлек мираска алынып даими (чикләүләрсез) файдалануга бирелгән һәм андый җир кишәрлеге шәхси милектә булган физик затлар искәрмә булып тора;

14) җир кишәрлеге, “Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең әйләнеше турында” 2002 елның 24 июлендәге № 101-ФЗ Федераль законда билгеләнгән очракларда, крестьян (фермер) хуҗалыгына яки авыл хуҗалыгы оешмасына бирелгәндә;

15) территория чикләрендә ясалган җир кишәрлеге Россия Федерациясе Шәһәр төзү кодексына таянып, территориянең комплекслы үсеше турында шартнамә төзелгән затка, яисә Россия Федерациясе яки Татарстан Республикасы тарафыннан төзелгән һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзү кодексына таянып территояриянең комплекслы үсеше мәсьәләләренең үтәлешен тәэмин итүче юридик затка;

16) җир кишәрлеге федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары нигезендә беренче чиратта яки чираттан тыш җир кишәрлегенә ия булу хокукы булган гражданнарга бирелгәндә;

17) җир кишәрлеге гражданнарга торак пункты чикләрендә шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, үз ихтыяҗларына бакчачылык өчен РФ ҖК 39[18] статьясының 5 пунктында каралган очракларда бирелгәндә;

18) җир кишәрлеге гражданин яки юридик затка арендага бирелеп, дәүләт яки муниципаль ихтыяҗ өчен тартып алынган җир кишәрлеге урынына бирелгәндә;

19) җир кишәрлеге дини оешмаларга, Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән территориядә авыл хуҗалыгы производствосын гамәлгә ашыру, казак җәмгыятьләренең традицион яшәү һәм хуҗалык итү рәвешен саклау һәм үстерү өчен Россия Федерациясе казак җәмгыятьләре дәүләт реестрына кертелгән казак җәмгыятьләренә (алга таба - казак җәмгыятьләре) бирелгәндә;

20) җир кишәрлеге, дәүләт яки муниципаль ихтыяҗ өчен резервта булган яисә аның әйләнеше чикләнгән булса, РФ ҖК нигезендә дәүләт яки муниципаль милектә булган җир кишәрлеген сатулашуларсыз, шул исәптән, түләүсез, алу хокукына ия булган затка бирелгәндә;

21) җир кишәрлеге гражданинга печән чабу, авыл хуҗалыгы малларын көтү, яшелчәчелек өчен яисә торак пункты чикләренең аръягында урнашкан җир кишәрлеге шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен;

22) җир кишәрлеге, файдалы казылмалар буенча эш алып бару өчен, файдалы казылмалар белән эш итүчегә бирелгәндә;

23) махсус икътисадый зона чикләрендә яки аның янында урнашкан җир кишәрлеге махсус икътисадый зона резидентына яки идарәче компаниягә, аларны махсус икътисадый зона турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җәлеп иткән очракта, махсус икътисадый зона чикләрендә һәм аның янындагы территориядә федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет, бюджеттан тыш финанс чыганаклары хисабына күчемсез милек объектлары төзү буенча функцияләр башкару һәм әлеге һәм алдарак төзелгән күчемсез милек объектлары белән идарә итү өчен бирелгәндә;

24) теләсә нинди төрдәге махсус икътисадый зона чикләрендә яки аның янында урнашкан җир кишәрлегендә әлеге махсус икътисадый зонада инженерлык, транспорт, социаль, инновацион һәм башка инфраструктура объектлары төзү һәм (яки) реконструкцияләү өчен Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтләре бирелгән федераль башкарма хакимияте органы, яки Россия Федерациясе субъекты булган башкарма хакимият органы, яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтләре бирелгән федераль башкарма хакимияте органы махсус икътисадый зона белән идарә итү өчен идарәче компания билгеләгән һәм вәкаләтләр бирү өчен “Россия Федерациясенең аерым икътисади зоналары турында” 2005 елның 22 июлендәге № 116-ФЗ Федераль законга туры китереп махсус икътисадый зона инфраструктурасы үсеше тармагында хезмәттәшлек турында килешү төзелгән затка;

25) концессион килешү каралган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле җир кишәрлеге, дәүләти-хосусый партнерлык турында килешүдә каралган җир кишәрлеге, муниципаль-хосусый партнерлык турында килешүдә каралган җир кишәрлеге, әлеге килешүләр төзелгән затка бирелгәндә;

26) җир кишәрлеге коммерция өчен кулланылышлы ялланган йорт төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү яки социаль кулланылыш өчен ялланган йорт төзү һәм эксплуатацияләү максатларында

территорияне үзләштерү өчен коммерция өчен кулланылышлы ялланган йорт төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү яки социаль кулланылыш өчен ялланган йорт төзү һәм эксплуатацияләү турында шартнамә төзелгән затка бирелгәндә, Татарстан Республикасы законнарында каралган очракларда, Татарстан Республикасы яисә муниципаль берәмлек социаль кулланылыш өчен ялланган йорт төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү өчен оештырган коммерциячел булмаган оешмага;

27) махсус инвестиция контрактында каралган эшчәнлекне тормышка ашыру өчен кирәкле җир кишәрлеге махсус инвестиция контракты төзелгән затка бирелгәндә;

28) сунарчылык төрләрен тормышка ашыру өчен кирәкле җир кишәрлеге сунарчылык хуҗалыгы килешүе төзелгән затка бирелгәндә;

29) җир кишәрлеге сусаклагычлар һәм (яки) гидротехник корылмалар урнаштыру өчен бирелгәндә һәм әлеге объектларның урнаштырылуы территориаль планлаштыру документларында федераль, региональ һәм җирле дәрәҗәдәге объект буларак каралган булса;

30) автомобиль юлларына бүленгән полоса чикләрендә һәм юл буе полосасында урнашкан җир кишәрлеге «Россия автомобиль юллары» дәүләт компаниясенә үз эшчәнлеген башкару өчен бирелгәндә;

31) «Россия тимер юллары» ачык акционерлык җәмгыятенә эшчәнлеген башкару өчен кирәк булган җир кишәрлеге, тимер юл транспорты инфраструктурасының гомуми файдалану объектларын урнаштыру өчен бирелгәндә;

32) җир кишәрлеге территориаль үсеш зонасы резидентлары реестрына кертелгән территориаль үсеш зонасы резидентына, инвестиция декларациясе нигезендә әлеге зонада инвестиция проектын гамәлгә ашыру өчен бирелгәндә;

(әлеге пунктның таләпләре действуют до 23 декабря 2024 елның 23 декабренә кадәр шул датаны да кертеп гамәлдә);

33) җир кишәрлеге, су биологик ресурсларын бирү турында карар, балык промыслы участогын бирү турында шартнамә яисә су биологик ресурсларын файдалану шартнамәсе нигезендә, су биологик ресурсларын табыштыру (тоту) хокукына ия булган затка, әлеге карар яки шартнамәләрдә каралган эшчәнлекне тормышка ашыру өчен бирелгәндә;

34) җир кишәрлеге дәүләти һәм муниципаль милектәге балыклы участоктан файдалану шартнамәсе (алга таба – балыклы участоктан файдалану шартнамәсе) нигезендә товар аквакультурасы (товар балыкчылыгы) җитештерүче затка бирелгәндә;

35) әлеге корылма һәм аны урыны турында карарлар Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан кабул ителгәндә, җир кишәрлеге атом-төш җайланмаларын, радиация чыганакларын, атом-төш материалларын һәм радиоактив матдәләрне саклау пунктларын, радиоактив калдыкларны саклау пунктларын, саклагычларны һәм радиоактив калдыкларны күмү пунктларын урнаштыру өчен юридик затка бирелгәндә;

36) авыл хуҗалыгы производствосы алып бару өчен билгеләнгән җир кишәрлеге, әлеге җир кишәрлегенә яңа аренда шартнамәсе төзү турында мөрәҗәгать арендатор тарафыннан әлеге җир кишәрлегенә алдарак төзелгән аренда шартнамәсенең срогы беткәнче бирелү шарты белән, вәкаләтле органда әлеге җир кишәрлеге белән файдаланганда федераль дәүләт җир кконтроле (күзәтчелеге) кысаларында ачыкланган һәм төзәтелмәгән Россия Федерациясе законнарын бозу турында мәгълүмат булмаган арендаторга бирелгәндә;

37) җир кишәрлеге РФ ҖКның $39^6$ статьясының 3 һәм 4 пунктлары нигезендә яңа аренда шартнамәсе төзү хокукына ия булган арендаторга (РФ ҖКның $39^6$ статьясының 2 пункттагы 31 подпунктында күрсәтелгән җир кишәрлеге арендаторлары чыгарма булып тора) бирелгәндә;

38) җир кишәрлеге «Торак төзелеше үсешенә, туристлык инфраструктурасы объектлары булдыруга һәм территориянең башка үсешенә ярдәм турында» 2008 ел, 24 июль, № 161-ФЗ Федераль законга нигезләнеп бирелгәндә;

39) «Инновацион фәнни-технологик үзәкләр турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 29.07.2017 № 216-ФЗ Федераль закон нигезендә оештырылган инновацион фәнни-технологик үзәк, фонд территориясе чикләренә кертелгән җир кишәрлеген;

40) җир кишәрлеген "Төзелеш тармагында бердәнбер заказ бирүче" гаммәви-хокукый компаниясенең агымдагы елда һәм план периодында эшчәнлек программасына кертелгән инженерлык тикшеренүләрен, архитектура-төзелеш проектлауларын, реконструкцияләр, капиталь ремонт, капиталь төзелеш объектларын сүтү эшләрен тәэмин итү өчен, "Төзелеш тармагында бердәнбер заказ бирүче" гаммәви-хокукый компания турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 22 декабрендәге № 435-ФЗ Федераль законы нигезендә;

41) җир кишәрлеген "Территорияләрнең үсеше фонды" гаммәви-хокукый компаниясенә «"Территорияләрнең үсеше фонды" гаммәви-хокукый компания турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 29 июль, 2017 ел, № 218-ФЗ Федераль законда каралган

функцияләрне һәм вәкаләтләрнее башкару өчен, әгәр дә «Түләргә сәләтсезлек турында (банкротлык)» 2002 ел, 26 октябрь, № 127-ФЗ Федераль законда каралган нигезләр буенча күрсәтелгән гаммәви-хокукый компаниягә бирелгән җир кишәрлегендә төзелеп бетмәгән (капиталь төзелеш объектлары төзелеше) объектларны төзеп бетерү җир законнары һәм Россия Федерациясенең башка законнарында билгеләнгән чикләүләргә бәйле рәвештә мөмкин булмаса һәм Россия Фендерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә төзелешкә рөхсәт бирергә вәкаләтле башкарма хакимиятнең федераль органы, Татарстан Республикасы башкарми хакимият органы, җирле үзидарә органы тарафыннан расланса, хәлсезлеге (банкротлыгы) танылган төзүченең җир кишәрлекләре (аларга хокуклары) булмаган очракларда;

42) җир кишәрлеген «“Территорияләрнең үсеше фонды” гаммәви-хокукый компаниясенә «Бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында» 2002 ел, 26 октябрь, № 127-ФЗ Федераль законда каралган нигезләрдә.

